ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА

СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНА СӘЯХӘТ

ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА

СӘНГАТЬ ДӨНЬЯСЫНА СӘЯХӘТ

Болгар иле турында истәлек язмалар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1989

ББК 84(2Р-Тат)-4
Б 86

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫ ӨЧЕН

Бәйрәмова Ф. Ә.

Б 86 Сәнгать дөньясына сәяхәт: Болгар иле турында истәлек язмалар.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.— 48 бит.
ISBN 5—298—00125—4

Б $\frac{4803010200-205}{М\ 132(03)-89}$ 146—89

Издание для детей и юношества

Байрамова Фаузия Аухадиевна

ПУТЕШЕСТВИЕ
В СТРАНУ ИСКУССТВ

Записки об истории Волжской Булгарии

(на татарском языке)

ИБ № 5455

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтов.* Художнигы *А. Тимергалина.* Художество редакторы *Ф. Хәсьянова.* Техник редакторы *А. Газиззянова.* Корректоры *Р. Хәмидуллина.* Җыярга тапшырылды 26.04.89. Басарга кул куелды 16.06.89. ПФ 01202. Форматы 84×108¹/₃₂. Китап-журнал кәгазе. «Литературная» гарнитурасы. Кабарынкы басма. Шартлы басма табагы 2,52. Шартлы буяу-оттиск 2,94. Нәшер-хисап табагы 2,7. Тиражы 15 000 экз. Заказ З-200. Бәясе 10 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.

ISBN 5—298—00125—4 © Татарстан китап нәшрияты, 1989

Тарихка чакыру сүзе

Кадерле укучы!

Син инде XX гасыр азагында — фән-техника бик нык алга киткән, кеше акылы зур ачышларга ирешкән заманда яшисең. Телевизордан космонавтларның галәм киңлегенә сәяхәтләрен күзәтеп барасың, фәнни журналлардан зур галимнәрнең дөнья, аның үткәне һәм киләчәге турында кызыклы әңгәмәләрен укыйсың. Синең дә күзең бүген йолдызларда, күңелең исә әнә шул йолдызара очышлардадыр. Оч, хыяллан, эзлән! Ләкин вакыт-вакыт җиргә карап алырга да онытма син! Менә бу җирдә, без басып торган урында, моннан мең еллар элек кемнәр яшәде икән? Сиңа телен, моңын биргән татар халкының үткәне нинди? Синең ерак бабаларың нинди һөнәрләр белгән, дөньяның гүзәллеген сәнгать теленә ничек күчерә алган? Бүгенге көнгә борынгының нинди сәнгать истәлекләре сакланып калган? Менә бу кечкенә генә китапны укып чыккач, бәлки, син әнә шул сорауларга да җавап таба алырсың. Йолдызларга ашкынган күңелең тагы да баер, туган җирең сиңа тагы да матуррак, кадерлерәк булып тоела башлар. Бәлки, әле син үзең дә, шушы китапның яшь геройлары кебек, тарих белән, халкыңның үткәне, аның рухи байлыклары белән кызыксынып китәрсең һәм туктаусыз эзләнә торгач, культура хәзинәләребез турында әсәрләр тудырырсың.

Әнә шундый хыяллар белән мин сине Тарихка — татар халкының сәнгать дөньясы тарихына чакырам. Бир кулыңны, яшь укучым! Безгә әле синең белән бик ерак барасы...

Автор

Күренекле галим, сәнгать белгече,
остазым Фоат Хәсән улы Вәлиевнең
якты истәлегенә багышлыйм.

Җайдаклар

Урман уртасында түгәрәк күл.

Бу күлне инде малайлар йөз мәртәбә йөзеп чыккандыр. Олылар гел әйтеп тора торуын: «Уртасына хәтле кермәгез, төбе юк ул күлнең»,— диләр. Ә малайларга нәрсә? Аркылыга-буйга гизделәр инде алар күлне! Әле чумып-чумып та карыйлар — чынлап та төбе юк микән бу күлнең?

Ногман да бүген көнозын күл буенда кайнашты. Күлнең уртасында төбе юк, дигәнгә ул бөтенләй ышанмый иде — чумган саен кулы җиргә тия бит аның. Әле шуңа ышансыннар өчен, бер уч умырып балчык та алып менә. Бу юлы да ул күлнең уртасына ук чумды да кулын ләмгә батырды. Бармаклары йомшак ләмгә түгел, ниндидер каты әйбергә килеп төртелде. Малай авыртудан кычкырып җибәрә язды, ләме-ние белән шул әйберне эләктереп алды да бөке булып өскә атылды.

Күл өстенә чыгуга, учын җәеп, табылдыгына карады. Юк, бу ләм түгел иде, таш та түгел иде, бу әле моңарчы Ногман күрмәгән әллә нинди сәер нәрсә иде.

— Малайлар, Ногман нәрсәдер тапкан!

— Алтын, алтын!

— Хәзинә тапкан, хәзинә!

Барысы да Ногман янына күл читенә ашыктылар. Чирәмгә утырып, табылдыкны әйләндерә-әйләндерә карый башладылар. Өстеннән ләмен сөртеп, су үсемлекләрен алып ташлагач, малайларның кулында искиткеч матур, нәкъ менә чын кебек итеп ясалган җайдаклар сыны торып калды. Алар үзләре атка атланган, ә атлары бербересенә арт белән баскан. Кояшта тиз үк кибеп, бу нәни җайдакларның нәни атлары малайлар кулында ялтырашып яталар иде. Менә хәзер җайдаклар аларның уч төпләреннән



сикерешеп төшәрләр дә, оран салып күл буйлап чабып китәрләр кебек. Ногман табылдыгын кысыбрак тотты.

— Карагыз әле, нәрсә икән бу?

— Әйдәгез, Болгарга йөгердек. Анда җир казый торган абыйлар беләләрдер әле.
— Археологлар диген. Казаннан килгән бит алар.

— Әйдә шуларга күрсәтәбез.

Малайлар авыл ягына таба йөгерделәр. Иң алдан, бәхет кошы тоткандай, Ногман йөгерә иде. Аннан ныграк йөгерүчеләр булса да, бу юлы Ногманны узарга кыймадылар. Ногман бүген хәзинә табучы иде, Ногман герой иде!

Тузан туздырып үзләренә таба йөгереп килүче малайларны археологлар да күреп алдылар. Арыган билләрен турайтып, эшләреннән туктап, аларны көтеп алдылар.

Мышкылдаган малайлар, сүзләрен дә әйтә алмыйча, барысы бер урынга өелделәр, дәшми генә Ногманны алгарак этәрделәр. Ногман учын ачып җибәргәч, җайдаклар кояш нурыннан кыймылдашып куйган кебек булдылар, атлары хәтта кешнәгәндәй иттеләр. Археологларның да арулары юкка чыкты, барысын онытып, табылдык өстенә иелделәр.

— Йосыф Галиевич, карагыз әле, бу бит Болгар чорыннан сакланган чакма ташы,— диде археологларның яшьрәге, янындагы ак чәчле ир-артка карап.

— Әйе шул,— диде Йосыф абый дигәннәре.— Егетләр, кайдан таптыгыз сез моны?

— Рабига күленнән, абый. Чумган идем... менә шушы нәрсәне таптым.

Йосыф Галиевич җайдакларны кулына алды да бик җентекләп карый башлады, бармаклары сак кына җайдаклар өстеннән шуып үтте. Малайлар гаҗәпләнеп бер җайдакларга, бер бу өлкән кешегә карадылар. Ногман сорамыйча түзә алмады:

— Абый, нәрсә соң бу?

Йосыф Галиевич әкрен генә бер таш өстенә килеп утырды. Малайларның юеш, кара чәчле башлары аша әллә кайларга киткән иде карашы. Малайлар да, аңа

ияреп, шул якка борылып карадылар. Берни юк. Җимерек ташлар өеме генә. Аннан, сабырсызлана башлап, тагы җайдакларга текәлделәр. Нәрсә икән соң бу?

— Бу безнең тарих инде, балалар.— Чал чәчле галим әллә малайларга, әллә әнә шул таш өемнәренә, әллә җайдакларның үзләренә сөйли иде.— Менә бу җайдаклар беләсезме кемнәр алар? Күкләр хуҗасы Тәңре һәм Яшен алласы Куар. Тик бу бронза сыннарны кешеләр — моннан мең еллар элек безнең борынгы болгар бабаларыбыз ясаган. Бу сыннар бабаларыбыз өчен зур мәгънәгә ия булган — борынгы халык аларга ут бирүче, ут саклаучы тылсымлы көч итеп караган.

— Ә утны... ничек биргән соң алар? Күктән алып төшепме?

Йосыф Галиевич Ногманның чәченнән сыйпап куйды.

— Юк, энем. Ул заманда инде утны күктән генә көтеп утырмаганнар. Безнең болгар бабайларыбыз бик зиһенле, көчле, тырыш халык булган. Менә бу җайдаклар рухи мәгънәгә генә ия булып калмаганнар — чын-чынлап ут чыгару өчен дә хезмәт иткәннәр. Җайдаклар да, аларның атлары да бронзадан ясалган. Ә алар астагы тимер пластинкага беркетелгәннәр. Һәм бу җайланма үзе кресалочакма дип атала. Аның тимерле өлешен чакма ташына бәреп, ут чыгарганнар. Арасына, гадәттә, кипкән мүк салып калдырганнар. Менә шулай итеп, безнең борынгы бабаларыбыз ут таба торган булганнар.

— Алар... ул чакмалар бөтен кешедә дә булганмы соң?

— Күбесендә булган. Ир-атларның бил каешларында чакмаларын саклау өчен махсус кесәчекләр булган. Сугышчылар да чакмаларын һәрвакыт үзләре белән йөрткәннәр. Хатын-кызның да йортта, учак янында шушындыйрак чакмалары булган булырга тиеш. Менә бит ул, тотарга да ничек җайлы, ипле итеп эшләнгән.

Чыннан да, җайдаклар урнаштырылган өлеше дугаланып та тора икән. Еллар буе ышкый-ышкый шулай дугаландымы икән әллә ул? Ике җайдак арасында бармак сыярлык урын бар. Анысы өстән җайлап тоту өчен булырга тиеш. Кара син бу бабайларны! Бөтенесен җайлаганнар! Җайдакларны ике бармак арасына кыстыр да алардан ут сора. Нинди сын ясарга кирәген дә белгәннәр бит — Тәңре һәм Яшен алласы Куар! Ут табу ысулын үзе уйлап чыгарса да, барыбер илаһи көчләргә табынган, алар ярдәменә ышанган борынгы халык...

Бронза чакма тагы кулдан-кулга китте. Малайлар хәзер инде аңа ят бер табылдык итеп кенә түгел, борынгы бабаларыбыз тормышында бик кирәк булган бер әйбер итеп карадылар. Үзе гади, үзе җайлы, үзе нинди мәгънәле һәм кирәкле! Ут алар өчен җирдә иң кадерле, иң кирәкле нәрсә булган бит! Утны сүндермичә тәүлекләр буе саклаганнар, учак тирәсендә һәрвакыт кеше тотканнар. Учакларында утлары сүнгән кешеләр, чүлмәк тотып, күршеләренә утлы күмергә йөгергәннәр. Салкында — җылыткан, караңгыда — яктырткан, борынгы халыкны ризык пешерергә өйрәткән, җирдә иң изге нәрсә ут булган. Менә бу җайдаклар — шуның кечкенә генә бер тарихы. Ут саклаучы, ут табучы җайланма. Борынгы көннәрдән бүгенгә хәтле килеп җиткән истәлек.



Аны бит Ногман үзе тапты, күл төбеннән тапты. Ә күлнең төбе юк дигән булалар тагын...

Кара пулат

Көн кичкә авышкан иде инде.

Археологлар Ногман тапкан җайдакларны яхшылап төреп сумкаларына салдылар да кайтырга кузгалдылар. Малайлар төркеме дә аларга иярде.

Ногман бу якларга әле күптән түгел генә әти-әниләре белән күчеп килде. Килүләренең икенче көнендә үк әллә кайдан күренеп торган биек манара янына чыгып йөгергән иде. Аннан соң Ногман бу тирәләрдә күп булды, туристлар артыннан да ияреп йөрде, малайлар белән дә әллә ничә тапкыр килгәне бар монда. Бу җирләрдә ул моннан мең еллар элек Болгар шәһәре торганлыгын, татар халкының борынгы бабалары саналган болгарларның

да шушы җирдә яшәгәннәрен белә инде ул. Хәзер ул борынгы шәһәрдән таш өемнәре, менә шушы манара һәм берничә җимерелеп бетмәгән бина гына калган. Шуларның берсе Ногманны бигрәк тә шомландыра. Халык телендә бинаны Кара пулат дип атап йөртәләр. Ни өчен Кара пулат икән соң ул? Әллә төрмә булдымы икән анда? Әгәр Йосыф абыйдан сорап карасам?

— Йосыф абый, менә бу бинаны нигә Кара пулат дип йөртәләр икән? Эче дә кап-кара бит аның...

Археологлар адымнарын әкренәйттеләр, зур-зур таш өемнәре арасыннан калкып торган Кара пулат каршында туктап калдылар. Инде караңгы төшкән иде, Кара пулат тагы да шомлырак, серлерәк булып күренә. Малайлар бер-берләренә якынрак елыштылар. Йосыф Галиевич Кара пулатның стенасына сөялде дә бераз уйланып торды. Аннан, малайларга карамый гына, үз-үзенә сөйләгәндәй, башлап китте:

— Халык арасында бер риваять — легенда йөри. Аксак Тимер Шәһре Болгарга бәреп керә, аны яндыра-җимерә башлый, кешләрне үтертә. Болгар ханы Габдулла үзенең гаиләсе белән менә шушы бинага кереп бикләнә. Аксак Тимер моны белеп ала һәм бинаны бүрәнәләр белән әйләндереп алып, аңа ут төртергә әмер бирә. Янгын бик куркыныч була, бөтен бинаны чорнап ала. Инде бина эчендәгеләр бөтенесе янып беттеләр дигәндә, мәйдандагы халык «Аһ» итеп түбәгә карый. Анда, котырынган ялкын телләре арасында, ап-ак күлмәкле бер кыз басып тора икән. Ул шул хәтле гүзәл була, аның бу гүзәллеге, кыюлыгы явыз ханны да таң калдыра. Ул шундук утны сүндерергә боера. Һәм, барысына да ишетелерлек итеп, бу кыю кызны үзенә хатынлыкка алырга теләвен әйтә. Әмма болгар ханының төпчек кызы горур һәм зирәк кыз була. Бу ерткыч ханның хатыны булганчы, үлемне артыграк күрүен әйтә. Ярсыган Аксак Тимер аның әсиргә төшкән ике абыйсын китертергә куша. Абыйларының муеннарына асылган тимер камытларны күргәч, хан кызы агарып китә һәм үзенең ризалыгын белдерә. Тик аның бер шарты була — ул үзенең күз алдында абыйларын иреккә җибәрүләрен, аларга иң яхшы атлар бирүләрен сорый. Аксак Тимер шундук бу ике егеткә иң яхшы аргамагын китертә. Егетләр атларга сикереп менәләр дә, сеңелләренә соңгы сәламнәрен биреп, кара урман эченә кереп югалалар. Хан кызы, алар күздән югалуга, аска, әле янып бетмәгән бүрәнәләр өстенә сикерә... Горур болгар кызы әнә шулай һәлак була. Ә аның абыйлары, урман эчләреннән бара-бара, Казан суы буйла-



рына ук килеп җитәләр һәм шунда яшәп калалар. Болгар нәселе башка урында — Казан җирендә дәвам итә...

Йосыф Галиевич сөйләп бетерүгә, Ногман, сәерсенеп, өскә күтәрелеп карады. Кара пулатның гөмбәзе өстендә, ап-ак күлмәкле болгар кызы басып торадыр кебек тоелды аңа. Аларның баш очыннан гына шаулап самолет очып узды. Казан ягына таба. Болгардан — Казанга, Казаннан — Болгарга...

Малайлар юл буе Болгар турында, ханнар, яулар турында сөйләшеп кайттылар. Инде төн иде, тирә-як әллә нинди шомлы, хәвефле иде. Шуңа күрә малайлар кычкырып-кычкырып сөйләштеләр, юри шаркылдашып көлгән булдылар. Ә артка борылып карарга барыбер курыктылар. Ногман гына һаман каерылып-каерылып шул якка карады, артта ялгыз манара сураеп утыра, ә Кара пулат өстендә ак күлмәкле болгар кызы түгел, классташы Зөлфия басып торадыр кебек тоелды аңа. Әле нәрсәдер кычкырган да кебек булды. Аннан барысы да төн караңгылыгында юкка чыкты, юкка чыкмады, малайның күңеленә күчте, җанында яши башлады.

Канатлы елан

Археологлар янынпан киткәндә, аларның яшьрәге, Рәүф абый дигәне, Ногманга кечкенә генә бер китап биреп җибәргән иде. Өйгә кайткач, ул аны тиз-тиз генә карап чыкмакчы иде дә, күзе бер рәсемгә төшеп, кисәк туктап калды. Рәсемгә канатлы елан сурәте төшерелгән иде. Елан гынамы әле! Аның башы — этнеке, гәүдәсе һәм канатлары — бөркетнеке, койрыгы — еланныкы. Башында әле кыр кәҗәсенеке кебек мөгезләре дә бар. Авызыннан, ялкын кебек, озын теле бәреп чыккан. Аның бөтен гәүдәсе балык кабырчыгы — тәңкәләр белән капланган. Ногман рәсемгә бик озак карап торды. Менә-менә канатлы елан китап битләреннән шуышып чыгар да җилпенеп очып китәр кебек тоелды аңа. Очып арыгач, суга төшәр, балык кебек ясалган бит ул әнә. Җирдә дә йөри ала. Бик мәгънәле җанвар булган бит бу. Ну, хәзер булса, котларын алыр иде малайларның. Өйләреннән дә чыгарга куркып утырырлар иде.

Улының, салган ашын да ашамыйча, һаман китап актарып утыруын күргәч, Гөлҗамал апа да гаҗәпләнеп куйды. Җәй көне Ногман китапларын тотып та карамый иде. Нигә шулай дөньясын онытты икән бу бала?

Ана да китап өстенә иелә төште.

— Менә бу җанварның нәрсә икәнен беләсеңме, әни?

— Бумы? Бу — аждаһага охшаган, улым. Аждаһа бу, канатлы аждаһа. Әүвәл безгә шундый экиятләр сөйли торганнар иде.

Ногман әнисенә елмаеп карап куйды. Һаман шул экиятләргә кайтарып калдыра әнисе. Әкият кенә булырга охшамаган әле монда!

Малай җайлабрак утырды да китапның канатлы елан турында язылган урыннарын укый башлады. Башта ул бернәрсә дә аңламады. Китап шактый катлаулы, фәнни телдә язылган иде. Теге археолог абый үзе кызыграк сөйләгән иде. Шуннан гына сорыйсы калган икән.

— Я, улым, миңа да укып күрсәт инде. Аждаһа дигәнме?

Ногман аптырап ук калды. Үзе дә берни белмәгәнне әнисенә ничек төшендереп бирсен инде ул? Шулай да, бутала-бутала, сөйләргә тотынды:

— Аждаһа ук димәгән ул аны, әни. Элек, әллә кайчан, моннан мең еллар элек, менә шушындый рәсем төшерелгән түгәрәк тимерләрне... Алар... ни... аел дип атала икән...

Менә шул түгәрәк тимерләрне сугышчы ирләр тагып йөргәннәр. Әле хазар дигәннәренең шушы сурәт төшерелгән бакыр байраклары да булган. Яуга шуны күтәреп барганнар.

— Нәрсәгә шушындый куркыныч сурәт тагып йөрделәр икән соң алар? Ә, улым?

— Алар аны, әни, киресенчә, курыкмас өчен такканнар. Шуны тагып куйгач, аларда ышаныч, батырлык арткан. Соңрак бу сурәт Болгар дәүләтенең гербы булган дигән фикер дә бар икән. Аннары, болгар шәһәрләре җимерелгәч, болгарлар белән бергә, бу герб Казан ханлыгына күчкән. Аларның дәүләт гербы булып киткән. Менә монда шулай дип язылган.

— Гербын-фәләнен белмим, әмма бик зур, бик матур шәһәр булган дип сөйлиләр шул Болгарны.— Гөлҗамал апа кулына китапны алып карый башлады.

— Без бүген шунда булдык, әни. Их, без ишеткәннәрне ишетсәң син бүген! Монда бит элек әллә кемнәр яшәгән...

Малай, бутала-бутала, ашыга-ашыга, энисенә үзе тапкан җайдаклар турында, Кара пулат, һәлак булган хан кызы турында сөйләргә кереште. Гөлҗамал апа тыңлап та, аңлап та өлгерә алмады, тик зиһене белән шуны төшенде — малаена әллә нәрсә булган иде. Көнозын су буеннан кайтмаган, өйгә кергәч, телевизордан башканы белмәгән малай бүген, дөньясын онытып, хан заманындагылар белән саташып утыра иде. Нәрсә булыр бу?

Ананың күңеле бу фалны яхшыга юрыйсы килде. Әнә бит, бер көн эчендә дөнья кадәр нәрсә белеп кайткан. Ә белемнең әле беркемгә дә зыян китергәне юк...

Ногманның исә төшенә бүген ак күлмәкле болгар кызы керде. Ногман вертолет белән килеп чыккан икән дә хан кызын янып торган сарай өстеннән тартып алган икән. Ә аста, котлары чыгып, аждаһа, аждаһа, дип кычкырып, бу урыннан качалар, йөгерәләр икән. Ул арада вертолет канатлы еланга әйләнә икән дә, хан кызы белән Ногманны утыртып, Казан ягына таба очып китә икән. Берзаман чәчләре җилгә таралган хан кызына караса, хан кызы да

түгел, классташы Зөлфия икән. Зөлфия чытырдап Ногманның кулына ябышкан. Ә Ногман көлә генә, курыкма, ди, мин хәзер күп нәрсәләр беләм, сине дә коткарырмын, ди. Ә үзләре һаман очалар да очалар икән...

Сыңар алка

Икенче көнне иртән Ногман тагы Болгарга, археологлар янына барырга булды. Алар янында кызык иде, алардан әллә нәрсәләр ишетергә мөмкин иде. Зөлфияләр яныннан үтеп барышлый, адымнары үзләреннән-үзләре әкренәйде. Зөлфия — алар классында иң матур, иң акыллы кыз. Бер Ногман гына түгел, бөтенесе шулай ди. Ногманның, иң беренче класска килеп керүгә, күзе аңа төште. Ул элек укыган мәктәптә мондый кызлар бөтенләй юк иде. Ул тезенә төшеп торган чем-кара чәчләре, ул сызылып кына киткән кара кашлары, ап-ак йөзе. Нәкъ әкиятләрдәге хан кызы инде. Болгар кызы... Әллә ул да борынгы ханнар нәселеннәнме икән?

Зөлфия бакчада, чәчәк түтәлләре арасында йөри иде. Ногманның әкрен генә үз турыларыннан үтеп барганын күреп, койма аша үрелеп карады.

— Сине кичә хәзинә тапкан диләр. Күрсәт әле.

Ногман сөрлегеп туктап калды.

— Ә мин аны... археолог абыйларга илтеп бирдем инде.

Сүз беткән иде. Икесе дә, уңайсызланып, башларын читкә борды. Ногман инде кузгалам дигәндә, аны тагы Зөлфия тавышы туктатты:

— Карале, Ногман, миндә дә бер әйбер бар иде.— Кыз тагы кызарып чыкты.— Минеке дә түгел инде ул. Аны миңа Руслан бирде.

Руслан исемен ишетүгә, Ногман каршында яткан ташны тибеп җибәрде. Таш шапылдап коймага барып бәрелде. Яратмый иде Ногман Русланны. Үзе куштан, үзе ялганчы. Үзе әле һаман Зөлфия тирәсендә бөтерелә, өйләрендәге күпме әйберне Зөлфиягә ташыды инде ул. Бүләк биреп ярамакчы була. Зөлфиясен дә әйтер идем инде...

Ногман гарьләнде, гарьләнүен сиздермәс өчен, сызгыра-сызгыра Зөлфияләр турыннан үтеп тә китте. Әмма кыз аны үзе куып җитте.

— Син кара әле аның нәрсә икәнен,— диде ул Ногманның янәшәсеннән йөгерә-йөгерә.— Син кара әле... Мин аны кесәмдә йөртергә дә куркам.

Ногман, башын борып, Зөлфия ягына карамый түзә алмады. Ләкин карашы Зөлфиягә түгел, аның нәни учына төште. Кояшта ялт-йолт килеп, аның уч төбендә сыңар алтын алка ята иде.

— Каян алдың син моны?

— Руслан бирде дип әйттем бит инде. Ул аны миңа яз көне үк биргән иде инде.

Ногманның гомерендә дә мондый нәрсәне күргәне юк иде әле. Түгәрәк бөҗра эченә кечкенә генә үрдәк сыны уелган, үрдәкнең авызы ачык, аннан орлыкка охшаган әйбер күренеп тора. Бик нәфис итеп үрелгән өч чылбырга имән чикләвекләре формасындагы асылташлар асылган. Тик колак алкасыннан шактый зур иде ул.

— Каян алды икән Руслан йомран моны?

— Әйтми. Әй, туйдым инде мин аннан. Шул алкасын сылтау итеп, көн саен безнең капка төбенә килеп утыра. Үзе башта бирде, хәзер көн саен шуны кире алып карый. Әле кичә бөтенләй сорап килгән иде, алкага дип кереп киткәч, әни чыгармады. Кире ала инде ул аны. Ул гел шулай.

Ногман Зөлфияне кызганып куйды. Русланның танавына берне кундырасы килеп китте. Белер иде аннан Ногманның кем икәнен. Йомран...

— Без бу алканы башта Йосыф абыйга күрсәтеп карыйк әле, яме, Зөлфия?

— Күрсәтик соң...

Менә алар Болгар җирендәге иске чиркәү янына килеп туктадылар. Зөлфия шикләнеп Ногманга карады. Чөнки Зөлфиянең әбисе аның ул йортка керүен өнәп бетерми. Кыз Ногманга бу турында әйтергә уңайсызланды. Ногманның исә Зөлфияне тизрәк эчкә алып кереп китәсе килде, чөнки чиркәү нигезенә салынган борынгы болгар кабер ташларын Зөлфиягә күрсәтәсе килмәде аның. Сораша башласа, ни дип җавап бирерсең? Аның нигә шулай салынганын Ногман үзе дә белми бит.

Чиркәү-музей эчендә салкынча иде. Тар, караңгы коридордан тиз генә түргә үттеләр. Ә анда... кечкенә Болгар шәһәре! Әнә һәр манарасы, һәр төрбәсе, меңмиллион тапкыр кечерәйтелеп, үз урынына утыртып чыгылган. Бу могҗизадан Ногманның тыны кысылып куйды. Элек музей кечкенә генә бер бүлмәдә иде. Монда күчкәч, Ногманның әле үзенең дә кергәне юк иде. Малайның нәни крепость стеналарына кулларын тидереп карыйсы килде — чак тыелып калды. Зөлфия дә, шаккатып, Болгар шәһәренең макетына карап тора иде.

Йосыф Галиевичне алар үз бүлмәсендә, ниндидер сөяк, таш кисәкләрен бик җентекләп карап утырган чакта эзләп таптылар.

— Ә... Ногман дус, — диде ул эшеннән аерылмый гына.—Ошап китте әле сиңа Болгар, ә?

— Йосыф абый, менә бу кызның... Зөлфиянең бик матур алкасы бар. Сезгә шуны күрсәтергә килгән идек.

Йосыф Галиевич кулындагы сөяк кисәген бер читкә куйды да аларга таба борылды. Зөлфиянең кулындагы алканы күреп, аягүрә торып басты. Аннан нигәдер тәрәзә янына, яктыракка таба китте. Бүлмә буйлап йөренеп алды. Ул инде Ногманнарны бөтенләй күрми иде. Менә ул ашыгып өстәл янына килде дә алдындагы кәгазенә тиз-тиз нидер яза башлады.

— X—XI гасыр,— дип кабатлады ул үз-үзенә исбат иткәндәй.— Болгар осталары ясаган моны! Болгар осталары! Кара син бу нәфислекне, кара син бу мәгънәне! Сеңлем, кайдан алдың син моны?

— Таптым,— диде Зөлфия, кызарып. Дөресен әйтергә оялды.

— Ә үрдәге нәрсә аңлата соң аның, Йосыф абый? — дип, Ногман тизрәк Зөлфиягә ярдәмгә килде.

— Үрдәгеме? Үрдәге дә зур мәгънәгә ия аның, балалар.— Йосыф Галиевич Ногман белән Зөлфияне үз янынарак чакырды.— Легендалар әйтүенчә, бөтен дөньяны иксез-чиксез су дәрьясы каплаган булган, шунда ялгыз үрдәк йөзеп йөргән. Һәм беркөнне ул су төбенә чумган да томшыгында бер бөртек коры җир алып менгән. Шулай итеп, дөньяда җир барлыкка килгән. Монысы, әлбәттә, легенда, тик аны шушындый зур осталык, төгәллек белән сәнгать әсәрендә чагылдыру — монысы инде могҗизаның да могҗизасы. Ай, бу Болгар осталары!

Йосыф Галиевичнең шул кадәр мавыгып сөйләвенә Зөлфия дә ачылып китте.

— Йосыф абый, алка булганмы соң бу?

— Алкасын алка, тик чигә алкасы. Болгар хатын-кызлары аны чигәләренә тагып йөрткәннәр. Кайбер галимнәр аны кашбау дип тә атыйлар. Алкаларны ефәк бауга бәй-

ләп, бау очын чәч арасына яшерә торган булганнар. Менә болайрак итеп.— Галим алканы Зөлфиянең чигә турына куеп карады. Ногман, тын алырга да куркып, Зөлфияне күзәтте. Зөлфия бөтенләй үзгәреп, сәерләнеп киткән кебек тоелды аңа. Нәни алтын чылбырлар кызның алсу яңакларына тиеп-тиеп алалар, тонык кына зыңгылдашып куялар. Зөлфия, уңайсызланып, керфекләрен түбән төшерә.

Ногман каршында, моңсу гына елмаеп болгар кызы, тарихта шушы алтын алкалары гына сакланып калган болгар кызы басып тора иде...

Бер капчык хәзинә

Алтын алканы, әлбәттә, музейда калдырдылар. Ногман моңа сөенде генә. Аның хәзер Йосыф абыйсы өчен гел нәрсәдер эшлисе, гел нәрсә дә булса табып торасы килә иде. Ул, Зөлфиягә сиздерми генә, жентекләбрәк һаман аяк астына карап барды. Ә юлда эреле-ваклы таш кисәкләре һәм гап-гади пыяла ватыклары гына сибелеп ята иде. Беркем дә, Ногман килә дип, хәзинә әзерләп куймаган шул.

Зөлфия дә эндәшми. Килгәндә юл буе сөйләшеп килгән иде, ә хәзер бер сүз әйтми.

— Зөлфия, әллә алкаңны калдырганга үпкәләдеңме?

Зөлфиянең бит урталары кып-кызыл булып чыкты.

— Син бигрәк инде, Ногман... Нишләп үпкәлим ди. Тик менә Русланнан гына бераз куркам. Нәрсә дип әйтәбез инде аңа хәзер?

— Син курыкма, Зөлфия. Бергә барырбыз өйләренә, аңлатырбыз.

Зөлфия, «белмисеңмени син аны» дигән кебек, Ногманга карап куйды да дәшми генә юлын дәвам иттерде. Ләкин Русланнарга барып йөрергә туры килмәде аларга. Әллә кай урамнан атылып, каршыларына Руслан үзе килеп чыкты. Ул Ногманга шикләнеп кенә карап алды да Зөлфияне читкә чакырды.

— Бир,— дип пышылдады ул, Зөлфиягә тирләгән керле кулын сузып.

— Нәрсәне?

— Нәрсәне, нәрсәне... Алканы бир.

Сүзләрен ишетмәсә дә, Ногман аларның нәрсә турында сөйләшүләрен шундук аңлады. Теге алтын алканы таптыра Руслан.

— Без ул алканы музейга илтеп бирдек инде, — дип кычкырды ул Руслан ишетерлек итеп.

— Музейга?! — Руслан ялт итеп Ногманга борылып карады. Аның таза битләреннән әллә тир, әллә яшь бөртекләре тәгәри иде. — Синең ни эшең бар минем әйбердә?

Ногманның да ачуы килде. Нишләп аның әйбере булсын ул?

— Нишләп синеке булсын ул алка? Беләсең килсә, аны Болгар осталары ясаган. Син туганчы ук! Моннан мең ел элек!

— Ясаса?! Аны мин таптым. Сез аны урлап, әллә кемнәргә илтеп биргәнсез!

Зөлфия Русланга якынрак килде. Җиңеннән тартып, кычкыруыннан туктатмакчы булды.

— Без бит аны галимнәргә илтеп бирдек. Менә үзеңне дә алып барырбыз әле Йосыф абый янына. Ул сиңа алкаң турында үзең дә белмәгән нәрсәләр сөйләр.

— Кит әле, җүләр! — Руслан Зөлфияне читкә этеп җибәрде. Зөлфия ап-ак күлмәге белән тузанлы юлга барып төште. Битен куллары белән каплады да сулкылдап елап та җибәрде.

Ул арада Русланнан җилләр искән иде инде. Кара багана булып, артында тузан болыты гына утырып калды. Ногман бер Зөлфиягә, бер шул тузан өеренә карады. Ну, йомран! Эләгерсең әле бер.

Ногман Зөлфиягә торырга булышты, күлмәген кагышты. Зөлфия инде еламый иде, ул җитдиләнеп, уйчанланып калган иде.

Иртәгесен Зөлфияләргә Русланнын әнисе килеп керде. Йөзе борчулы, тавышы да калтыранып чыга иде аның.

— Кызым, аптырап синең янга килдем әле, — диде ул Зөлфиянең каршына утырып.— Безнең малайга әллә нәрсә булган. Бакча башындагы ташландык кара мунчага кереп бикләнде. Ашарга да чыкмый, кешене дә кертми. Атасына әйтергә куркам, мине тыңламый. Ишек артында тыңлап торган идем, әллә тимер, әллә сөякләрне шалдыр-шолдыр китерә шунда. Акылына җиңеллек килмәгәе дим. Һаман нәрсәдер җыя, нәрсәдер яшерә.

Зөлфия урыныннан сикереп торды. Сөйләргәме Русланның әнисенә алтын алка турында, юкмы? Бәлки әле, Руслан мунчада да әллә нәрсәләр яшереп ятадыр? Әнә шулай әрәм булган күпме тарихи әйберләр турында сөйләде бит Йосыф абый.

— Җәмилә апа, мин хәзер Ногманнарга барып киләм. Аннары нәрсә дә булса эшләрбез.

Зөлфия Ногманнарга чыгып йөгерде. Аңа тиз-тиз генә хәлне сөйләп бирде. Икесе дә бер фикергә килделәр — Руслан мунчада нидер яшергән. Теге алканың сыңары булырга да бик мөмкин. Ногман тизрәк Болгарга, Йосыф Галиевич янына йөгерде. Зөлфия Русланнарга бара торырга булды.

Руслан, чыннан да, кара мунчада бикләнгән булып чыкты.

Ул арада, бер-берсеннән ишетеп, мунча янына әллә никадәр бала-чага җыелып өлгерде. Кычытканнардан чактыра-чактыра, мунча тирәсендә таптана башладылар. Күпме генә дөбердәтсәләр дә, кара мунчаның ишеге ачылмады. Бакча сукмагыннан кызу-кызу атлап килүче Йосыф Галиевич тә күренде. Аңа Ногман һәм аларның класс җитәкчеләре Әнвәр Хаҗиевич та ияргән иде.

Аның килүе бик урынлы булып чыкты. Руслан бары тик Әнвәр абыйсы эндәшкәнгә генә җавап бирде һәм ишекне ачарга булды. Барысы да, могҗиза көткәндәй, шыгырдап ачылып киткән ишеккә төбәлделәр. Аннан, сискәнешеп, читкә сибелделәр. Ачык ишектән аларга йөзе-башы корымга, тузанга буялып, куркыныч бер кыяфәткә кергән Руслан карап тора иде. Янында — иске капчык, Руслан ул капчыкны нигәдер капларга, яшерергә тырыша. Барысы да, Русланны онытып, шул капчыкка текәлделәр. Беренче булып сүзне Әнвәр Хаҗиевич башлады:

— Сине хәзинә тапкан дип әйтәләр, Руслан. Әллә шушы капчыктамы соң яшерелгән хәзинәң? — Карт галим белә иде — бу тирәдә яшәүче халык, бигрәк тә яз көне, җир ачылгач, һаман нәрсә дә булса табып тора. Бәлки, бу малай да тарих өчен әһәмияте булган нәрсә тапкандыр?

Ул шулай дип әйтүгә, Руслан аягы белән капчыкны тагы читкәрәк этеп куйды. Капчыкта ниләрдер шылтырап, зыңгылдашып алдылар. Йосиф Галиевич агарынып китте һәм ныклы адымнар белән Руслан янына килеп басты.

— Энем, — диде ул Русланга төбәлеп карап, — әгәр син чыннан да хәзинә тапкансың икән, ул турыда иң башлап дәүләт органнарына хәбәр итәргә кирәк. Мунчада, капчыкта яшереп сакларга түгел.

— Сакласа... Мин аны үзем таптым. Минем үземнеке ул.

— Алайса болай итәбез...— Йосыф Галиевич як-ягына каранды, кесәләрен капшап алды, газета чыгарып, аны

мунча янындагы яшел чирәмлеккә җәйде.— Алып кил монда капчыгыңны. Карыйбыз хәзер, ташмы анда, әллә фән өчен бик зур бәһале хәзинәме.

Ул шулай диюгә, малайлар йөгерешеп барып капчыкка ябыштылар. Иске киндер капчык бик тиз чирәмлеккә күчеп утырды. Йосыф Галиевичнең әйткәнен дә көтмичә, дистәләгән кул капчык төбенә чумды. Һәрберсе нидер эләктереп, минут эчендә кире дә чыкты. Кайсысының кулында сынык сөяк кисәге, кайсысында күгәргән тимер, түгәрәк ташлар, ярты-йорты чылбыр, тагы йөзек-беләзекләргә охшаган бизәкле әйберләр иде. Йосыф Галиевич аларны газета өстенә куярга кушты һәм калган әйберләрне саклык белән генә үзе бушата башлады. Алган бер әйберне җентекләп карый, бала-чага кебек куана, һәрберсе турында бер-ике сүз белән булса да сөйләп алырга да өлгерә иде галим. Аннары ул Русланга күтәрелеп карады.

— Ачуланыргамы, рәхмәт әйтергәме инде сиңа, энем. Ачуланыр идең, син фән өчен искиткеч кызыклы әйберләр тапкансың. Рәхмәт әйтер идең, шул байлыкны айлар буе кара мунчада бикләп, дөньяга чыгармый тоткансың. Шулай ярыймыни инде...

Аннары ул тагы табылдыклар янына килеп тезләнде. Инде капчык бушаган, бөтен байлык газета өстендә сибелеп ята иде. Йосыф Галиевич шулар арасыннан кечкенә генә сөяк кисәген алды да аны малайларга күрсәтте.

— Менә моның, мәсәлән, нәрсә икәнен беләсезме сез? Белмәгәнегезне сизеп торам. Җәядән дә атып караганыгыз юкмы?

Малайларның үзләре ясаган җәядән атып караганнары бар барын. Ләкин бу кечкенә сөяк кисәгенең җәягә нинди катнашы булыр икән соң?

— Ук атылып киткәндә, җәя бавы тартылып, баш бармакны имгәтмәсен өчен, болгар сугышчылары җәя киергесенә менә шушындый сөяк җайланмалар бәйләп куя тор-

ган булганнар. Болгарлыларның мондый тапкырлыгына бер соклансаң, икенче килеп сөяк җайланманың матурлыгына, бизәлешенә таң каласың. Гадәти генә көнкүреш әйбере үзе, ә менә һәр бизәге ничек уйланып, төгәл һәм мәгънәле итеп эшләнгән. Сезгә күренә микән, менә шушы кечкенә генә әйбергә күпме сурәт төшерелгән. Ике якка ике урман тавыгы — суер баскан, өстә мәче башлы ябалак утыра. Аста әле әнә поши башы да

күренеп тора. Җайланманың ян-ягына дулкын-дулкын гөляфрак бизәкләре төшерелгән. Биредәге һәр бизәк, һәр җәнлек сурәте мәгънәгә ия. Төн кашы ябалак болгарлар өчен бигрәк тә зур көчкә ия булган. Аңа урман кошларының патшасы, юлчыларга, аучыларга уңыш китерүче зирәк кош итеп караганнар. Менә, энем, синең капчыкта аунап яткан бу сөяк кисәге күпме нәрсә турында сөйли ала. Син боларның күбесен бер тирәдән тапкансың инде. XII гасыр әйберләре болар. Бер йорт һәм, әйтергә кирәк, шактый югары катлау кешеләре яшәгән йорт урыны булган бу. Син боларны каян тапканыңны миңа күрсәтерсең әле.

Руслан эндәшмәде. Йосыф Галиевич сөйләгәннән соң, аңа сүз әйтерлек урын да калмаган иде инде.

Табылдыклар арасында бер-берсенә охшаган берничә тимер әйбер дә бар иде. Кайберләренең кырыйлары кителгән булса да, аларның кайчандыр түгәрәк булганлыгы сизелеп тора иде.

— Ә менә болары — болгар көзгеләре, — диде Йосыф Галиевич, саклык белән генә аларны кулына алып.— Мондый көзгеләрне казылмалар вакытында безнең очратканыбыз бар иде инде. Көзге, мөгаен, болгар чорында да хатын-кыз яшәгән һәр йортта булгандыр. Бронзадан эшләнгән бу көзгеләрнең бер ягына көмеш йөгертелгән булган, икенче ягына кош-җәнлек сурәтләре, гөл-чәчкә рәсемнәре, дугайланып-бормаланып киткән челтәр-челтәр бизәкләр төшерелгән. Сәнгать телен аңлый белгән кешегә бик күп нәрсәләр турында сөйли бу көзгеләр. Менә, мәсәлән, дүрт кош сурәте төшерелгән көзгегә карагыз әле. Казлар бит,

күрәсезме, нәкъ безнең йорт казлары. Римны ничек итеп казлар коткарганын сезнең ишеткәнегез бардыр, әлбәттә. Менә бу рәсемгә карап, ул миф болгарларда да булган, дигән, фикергә киләсең. Дошманнар шәһәргә якынлаша башлагач, болгар казлары да каңгылдашып, халыкны, сугышчыларны уятканнардыр, бәла-каза килүе турында кисәткәннәрдер...

Менә шулай итеп, Болгар осталары тимергә дә, бакырга да, сөяккә дә табигатьнең бик күп бизәкләрен төшереп калдырганнар. Җирнең барча байлыгына, матурлыгына, каш-кортына, үсемлекләр дөньясына — һәммәсенә дә сокланулары, хөрмәтләре зур булган аларның. Күргәннәрен сәнгатьле итеп, мәгънәле итеп аңлатып бирү ысулларын да тапканнар. Тик ташлар сөйли, сөякләр сөйли дип кенә уйламагыз сез. Алар аша үз дөньялары турында борынгы болгар бабаларыбыз сөйли безгә. Ә аларның дөньялары бик бай булган...

Йосыф Галиевич табылдыкларны төреп куенына салды.

— Иртәгә Болгарга килегез әле барыгыз да, — диде ул һаман берни эндәшми үзенә карап торган балаларга. — Сез бик бай тарихлы җирдә яшисез. Менә бүгенге кебек хәлләр килеп чыкмасын өчен, — ул тагын Русланга карап куйды, — җыелып сөйләшергә, бәлки, тарих-археология түгәрәге оештырырга кирәктер? Сез ничегрәк уйлыйсыз, Әнвәр Хаҗиевич?

Әнвәр Хаҗиевич, укучысының бүгенге кыланышларыннан җир тишегенә керерлек хәлгә килгән иде. Галимнең соравына ул куанып куйды, йөзе яктырып китте.

— Йосыф Галиевич, без барыбыз да иртәгә җыелып Болгарга килербез, — диде ул ышанычлы тавыш белән. — Бу җирнең тарихын анда яшәүчеләр яхшы белергә тиеш.

Болгар мунчалары

Җәй көне булса да, бала-чага таралмаган иде. Каникулларын күбесе үз йортында — шушы Болгар җирендә, Идел буенда уздыра иде. Әнвәр Хаҗиевичка да өйдән-өйгә укучыларны чакырып йөрергә туры килмәде — иртән барысы да Ногманнар капка төбенә җыелып өлгергәннәр иде инде. Тик Руслан гына башта алар янына килергә кур-

кыбрак торды, төркем Болгар ягына карап кузгалгач кына, бераз ара калдырып, артларыннан иярде.

Йосыф абыйлары аларны урамда ук каршы алды. Әкрен генә искән җил аның ак чәчләрен кузгатып куя, аннан таш арасында үскән әремнәрне чайкалдырып уза. Йосыф абыйлары бүген серле әкиятче кебек. Шул әкиятләр иленә ул менә хәзер Ногманнарны да алып кереп китәчәк...

— Менә, балалар, сез Шәһре Болгар урынында басып торасыз инде, — дип башлап китте галим үзенең сүзен. — Идел елгасы буендагы искиткеч җайлы һәм матур бу урынга болгарлар Азов буйларыннан VIII гасырда ук күчеп килә башлаганнар. Шушында шәһәр салганнар, көн иткәннәр, чит дәүләтләр белән элемтәдә торганнар. Болгар дәүләте, гомумән, шәһәрләр иле булган. Бүгенгесе көндә безгә ул заманның 157 шәһәр урыны билгеле, шуның 38е бик зур шәһәр, 71е кечкенә шәһәрлек һәм алардан кала хәрби пунктлар, феодал замок урыннары. Зур шәһәр дигәннәре берничә дистә, хәтта берничә йөз гектар мәйдан җирне билән торган. Шәһре Болгар да матурлыгы һәм байлыгы турында даны ерак Европа илләренә хәтле барып җиткән шанлы шәһәр булган. Зур-зур хан сарайлары, торак йортлардан тыш, биредә ак таш пулатлар, төрбәләр, мәчет һәм мунчалар булган. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән истәлекләрдән — әнә шул бер көн күрсәткән Кара пулат һәм Кече манара, тагы берничә төрбә генә сакланып калган. Мунча урыннарының эзләре бик ачык төсмерләнә. Шәһре Болгарда биш җәмәгать мунчасы булган. Ак пулат һәм Кызыл пулат дип аталганнары турында безгә бигрәк тә яхшы билгеле. Чөнки әле алар XIX гасыр азагында гына җимерелеп беткәннәр. Әйдәгез, мин сезгә шул мунча урыннарын күрсәтәм.

Юл күрсәтүче башлык кебек, Йосыф Галиевич алдан атлап китте. Аның артыннан гөжләшеп балалар төркеме иярде. Монда хәзер урамнар да юк, юл да, сукмак та юк иде. Кая карама, чокыр-чакыр да таш өемнәре. Алар арасында котырынып кыргый үлән үсә, әрекмән һәм кычыткан хакимлек итә. Менә зур-зур таш савытлар утырып торган җиргә килеп җиттеләр. Бу кайчандыр данлыклы болгар мунчасы урнашкан урын иде.

— Мунча салдыру Идел буе болгарларының ислам дине белән, ягъни X гасырлар башында кергән булырга тиеш. Чөнки мондый мунчалар гомумән шәрык дөньясына хас күренеш. Болгар мунчаларының да Кырым, Азәрбайҗан, Мисыр, ягъни Египет мунчалары белән уртаклыгы бар. Охшаш яклары күп булса да, мунчалар барыбер



Болгар осталары кулы бебән торгызылган, барысы да инженерларча зур төгәллек белән уйланылган, болгарларга хас нәфислек белән башкарылган. Мунча стеналары алсу, зәңгәр, кызыл төсләргә буялган. Шуның өстенә сары, кызыл, кара буяулар белән таш өстенә бормалап-бормалап нәфис сызыклар төшерелгән, ул сызыклар, гөл-чәчкә бизәкләре белән аралашып китеп, җанны иркәли, тынычландыра торган серле бер дөнья хасил иткәннәр. Мунчаларның идәннәре ялтыратып шомартылган ак таштан җәелгән, ә түшәмнәре түгәрәк гөмбәз формасында булган. Тәрәзәләр шул гөмбәзләргә урнаштырылган — алар яшел төстәге калын пыяладан эшләнгәннәр. Мунча эченә яктылык әнә шул түшәмдәге тәрәзәләрдән төшкән. Ә кичләрен исә зур-зур асылмалы шәмдәлләр яндырылган. Бу мунчалар юыну урыннары гына түгел, үзенә күрә клуб, фикер алышу, күңел ачу урыннары да булып торган.

Ногман төркемнән бераз аерылып китте дә зур таш савыт янына барып басты. Бу савытлар су җыю өчен файдаланылган һәм стена буйларында тезелешеп торган. Ә су стеналар эчендәге балчык һәм тимер торбалардан килгән. Нәкъ хәзерге шәһәр мунчаларындагы кебек — кранны ачып җибәрәсең дә — кайнары кирәкме суның, салкынымы — рәхим ит. Ә моннан мең еллар элек эшләнгән бит шул мунчалар. Шушы Идел буенда яшәүче халыкның үз көче, үз акылы белән... Ногманның укыганы бар — әле бүгенгә хәтле мунчалары булмаган халыклар бар икән. «Ә үз халкыбыз соң? —дип уйлады ул,— шушындый затлы мунчалардан кара мунча хәленә калган халык?» Малай моныcына җавап таба алмады. Тагы кичәге хәлне, Русланнарның кара мунчасын исенә төшерде. Йосыф абый сөйләгән, тасвирлаган болгар мунчаларыннан соң, Русланнарның мунчасы кечерәеп, җиргә сеңеп, шыксызланып калган кебек тоелды.

Кабер ташлары ни сөйли?

— Болгарлар таш белән бик оста эш иткәннәр,— дип сүзен дәвам иттерде Йосыф Галиевич үзәк мәйданга кире кайтканда. — Ак таш күп булган, аны Идел буеннан чыгарганнар. Болгар үзе дә ак ташлардан төзелгән шәһәр булган бит. Һәм безнең көннәргә кадәр килеп җиткән истәлекләрнең дә күбесе шул ташларга чокылып ясалган, ташлардагы сурәтләр безгә борынгы бабаларыбыз турында күп нәрсәләр сөйли ала.

Тирмәгә охшаган тәбәнәк кенә бер бина янына килеп туктадылар. Аның ишеге тимер челтәрле булып, эченнән салкынлык бәреп тора иде. Балалар, шикләнешеп, бер тирәгәрәк өелделәр. Йосыф Галиевич тимер ишекне ачып җибәрде дә караңгылыкка таба атлады. Аңа балалар да иярделәр.

— Мин сезне бирегә кабер ташларын күрсәтергә алып кердем, — дип сүзен башлады Йосыф Галиевич. Шунда гына Ногман стена буйларына сөяп куйган ташларны күрде. Алар шактый биек иде, һәм монда кергән балаларга өстән кырыс кына карап торалар кебек тоелды. Ногманның тәне чымырдап китте. Үзе сиздерми генә Зөлфиягә карап куйды. Зөлфиянең дә күзләре зур булып ачылган, ул да, тын алырга куркып, шул кабер ташларына текәлгән иде

— Риваятьләр буенча, бу төрбәдә хатын-кызлар күмелгән булган, — дип сөйли бирде Йосыф абыйлары балаларны күзәтә-күзәтә.— Тик бу кабер ташлары бирегә, соңыннан аяк астында аунап ятмасын өчен, төрле урыннардан җыеп китереп куелган. Гарәпчә язылган сүзләрдән тыш, аларга төрле бизәкләр дә төшерелгән. Фән өчен бик кадерле бизәкләр алар. Биекләрен карарга буегыз җитмәсә, биредә менә аркылы куелганнары да бар. Бизәкләре дә шактый ачык сакланган.

Барысы да түргә таба борылдылар. Анда, авыру баһадирдай, заманнар үтү белән соры төскә кергән зур бер таш ята иде. Әйтерсең бу ташның өсте гел җәрәхәттән тора, анда — тирән-тирән сызыклар, уелып-уелып кергән чокырлар. Тимер челтәр аша кергән яктылыкта гына берни дә ачыкларлык түгел. Йосыф Галиевич моны үзе дә төшенеп алды һәм балаларга:

— Без, булмаса, музейга керик, анда кечерәк күләмле ташларны карарбыз, — диде. — Караңгырак та монда бераз. — Шулай диде дә үзе ишеккә таба атлады.

Руслан шуны гына көтеп торган диярсең. Йосыф Галиевич борылуга, ул, батыр бер кыяфәттә, теге дәү таш өстенә сикереп менде дә, кулларын кесәсенә тыгып, гамьсез генә таптана башлады. Кабер ташын күргәч бөтенесенең коты чыккан иде, менә белсеннәр әле Русланның кыюлыгын! Уйламый да өстендә йөри менә. Зөлфия күрә микән аның бу батырлыгын? Күрә, әнә шаккатып карап тора бит.

— Аягың корыр,— дип пышылдады Зөлфия малай ишетерлек итеп кенә.— Кабер ташына басарга ярыймыни? Төш тизрәк.

Руслан аның саен узынды. Аңа Зөлфиянең ялынуы кызык иде. Ул, шуңа ләззәтләнеп, кабер ташы өстендә аякларын тыпырдатып алды. Авыру таш ыңгырашып куйгандай булды. Бераз алгарак киткән Ногман борылып карады да, таш өстендәге тамашаны күреп, атылып Руслан янына килде. Алагаемга Русланны якасыннан эләктереп алып ишекнең теге ягына ук тотып атты. Балалар инде музейга таба киткәннәр иде, беркем берни күрми калды. Руслан тузан арасыннан мүкәләп торды да, йодрык күрсәтә-күрсәтә, авыл ягына таба йөгерде.

— Әле ярый, Йосыф абый күрмәде,— диде Ногман, әллә Йосыф абыйсын, әллә кабер ташын бу ямьсез хәлдән аралавына сөенеп.

Зөлфия дәшми генә аның кулларыннан җитәкләп алды. Ногманның куллары нык иде, җылы иде, һәм менә шушылай җитәкләшеп аның белән әллә кайларга да бара алыр кебек иде Зөлфия.

Йосыф Галиевич, дөньясын онытып, кабер ташларындагы бизәкләр турында сөйли иде.

— Менә бу түгәрәк боҗра эчендәге нурларны күрәсезме? Алар болгар чорындагы күп кабер ташларында очрый. Нәрсәне аңлата соң алар? Җирле халыкның күккә, кояшка, йолдызларга, айга табынган чакларында ук, әле язу булмаган вакытларда ук кулланылгандыр бу билгеләр.

Кешегә үлгәч тә, «теге дөньяда» да якты булсын өчен кабер ташларына кояш, ай, йолдыз билгеләре төшерелгән. Кайбер кабер ташларына сыгылмалы гөл-чәчкә, яфрак сурәтләре дә чокып ясалган. Болгарлар үзләренең якыннарын үлгәч тә әнә шулай кадерләп, зурлап искә ала торган булганнар.

Күк һәм кояшны символлаштырган сурәтләрдән тыш, кабер ташларында кош рәсемнәре дә очрый. Монысы инде борынгырак — ислам дине кергәнче үк куелган ташлар дип уйлыйм. Аның да үзенә күрә мәгънәсе булган. Борынгылар, кеше үлгәч, аның җаны кошка әйләнә дип уйлаганнар. Шулай итеп, болгарлар таш эшенә дә, сөяк, тимердән төрле сәнгать әйберләре ясауга да бик оста булганнар.

Йосыф Галиевич туктап торган арада, Зөлфия кыяркыймас кына сорап куйды:

— Йосыф абый, аларның галимнәре булганмы соң?

— Булмыймы соң, сеңлем... — Йосыф абыйлары чиркәү эченә чыгып басты, балаларны да үз янына дәште.— Күрәсезме, әле хәтта макетта да бу шәһәрнең очы-кырые күренми, әнә күпме урынны биләп ята. Мондый зур кала, мондый зур дәүләт белән идарә итү өчен, әлбәттә, ханнар да, ханнар янында галимнәр дә, галимнәр өчен мәктәп-мәдрәсәләр дә, анда йөрүче халыкны гыйлемле итәрлек әсәрләр язучы әдипләр дә кирәк булган. Болгарлар башта тамгалы язулар белән язганнар, аннан, 922 нче елда ислам динен кабул иткәч, гарәп язмасына күчкәннәр. Дин белән бергә шәрыкның зур әдәбияты килгән, тәэсир иткән. Аларга иярен, җирле халык тормышыннан мисаллар алып, болгар әдипләре зур-зур әсәрләр язганнар, галимнәр фәнни хезмәтләр тудырганнар. Бигрәк тә әхлак мәсьәләләре, дин, табигать, сәламәтлек турында фәнни хезмәтләр күп булган. Хәзер сезгә аларның исемнәрен әйтсәң дә, барыбер хәтерләмәссез. Менә көзгә кергәч, атнаның бер көнендә, дәресләрдән соң, мин сезгә бераз сабак бирермен. Шунда барысына да тукталырбыз.

Зөлфиянең үзенең дә бераз белгәнен әйтәсе килде. Юк, ул галимнәр турында белми, әмма ул «Кыйссаи Йосыф»ны белә! Алар өендә ул китапның әллә ничә төрлесе бар — гарәп хәрефләре белән язылганы да, безнеңчәсе, хәтта русчасы да бар! Соңгысы — Зөлфия өчен, Зөлфия бит рус классында укый, гарәпчә белми, татарча — авырлык белән генә укый. Ләкин ул барыбер «Кыйссаи Йосыф»ның татарчасын — матур рәсемнәр белән бизәкләп эшләнгәнен укыды! Әле ятлады да! Әбисе аннан, дога укыткан

кебек, һәр көн берничә шигырь сөйләтә, юк, сөйләтми, җырлата, көйләтә.

— Йосыф абый, мин дә болгарның бер шагыйрен беләм, — диде Зөлфия, батырчылык итеп.

— Шулаймы?! — Карт галимнең йөзе яктырып ук китте. — Менә бит, димәк, миңа ярдәмчеләр дә табыла дигән сүз. Я әйт әле, сеңлем, кем икән ул?

Барысы да Зөлфиягә текәлделәр. Зөлфиянең алсу йөзе тагы да алланды, ул әкрен генә шигырь әйтә башлады:

Газиз Йосыф тәмам унбер яшәр иде,
Йагъкуб сиүчи итәгендә йоклар иде,
Йоклаганда гаҗәп бер төш Йосыф күрде,—
Төш мәгънәсен атасыннан сорар имди:

«Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз
Шул төшемдә сәҗдә кылды миңа төп-төз,
Бу төшемне шулай күрдем, һичбер шиксез,—
Йә, эткәем, шул төшемне юра имди».

Ногман телсез калды. Зөлфияме бу?! Нинди матур, кызганыч шигырь сөйли ул?! Көйләп-көйләп, җыр җырлаган кебек итеп сөйли. Ногманның беркайчан да алай шигырь укыганнарын ишеткәне юк. Ул җыр да түгел, шигырь дә түгел, алардан да өстенрәк нәрсә, — нигә Ногманның күзенә яшь килә соң, нигә тәне дерелди, нигә йөгереп барып, шул Йосыф дигән малайны коткарасы килә? Нигә аның абыйлары шулай явыз икән — әнә бит, кеп-кечкенә энеләрен коега салып китәләр. Соңыннан Йосыф күпме газаплар күрә, ләкин абыйларын кичерә. Явызлыкны яхшылык белән җиңә...

Зөлфия туктаган икән. Әнә Йосыф абыйсы аның чәчләреннән сыйпап тора. Әллә бу Йосыф атлы кешеләр барысы да шулай яхшы булалармы икән? Әллә ул шул чорлардагы Йосыф дигән кешеме икән? Шул замандагы хәлләрне сөйләр өчен безнең көннәргә килдеме икән? Юк, алай булмыйдыр инде ул. Йосыф абый күп укыган, күп белә. Зөлфия дә белә икән әнә.

Йосыф абыйсының тавышы Ногманны уйлар дөньясыннан тартып чыгарды.

— Син шагыйрьләрнең иң зурысын беләсең, сеңлем, — ди ул әнә Зөлфиягә. — Син укыган шигырь Кол Гали дигән шагыйрьнеке ул. Аның язылуына инде 750 ел. Телдән-телгә күчеп йөри-йөри, безнең көннәргә дә килеп житте менә. Инде синең кебек балалар да яттан белгәч, мәңге яшәячәк инде ул.

Алар урамга чыктылар. Яктылыктан күзләр камашып

китте. Балалар җимерек мәчет урынындагы таш араларына таралдылар. Таш араларында җил кыштырдады, таш араларында кыргый үлән котырып үсә иде.

— Болгар шәһәрләренең матурлыгы, халкының зирәклеге, җирләренең уңдырышлылыгы, урманнарының киек-җәнлекләргә, кош-кортка байлыгы турында хәбәр еракеракларга барып җиткән, — дип дәвам итте Йосыф абыйлары.— Бу якларга кызыгып та, көнләшеп тә карый башлаганнар. Күп яулар кичерә Болгар иле, ләкин бирешми, яуда егылган сугышчылар урынына яңалары баса, җимерелгән шәһәрләр кат-кат торгызыла. Ерак монгол далаларыннан Чыңгыз хан баскыннары да яулар белән килә. Алар 1236 елны Шәһре Болгарны басып алалар. Ләкин Алтын Урда чорында да Болгар яшәвен дәвам итә. XIII гасырның ахыры, XV гасырның башында салынган таш пулатлар, күп төрле археологик истәлекләр әнә шул хакта сөйлиләр. 1361 елда Алтын Урда ханы Булат Тимер Болгарны басып алганнан соң, хан һәм вәзирләр белән бергә, 36 галимне дә астыра. Ләкин халык хәтле халыкны алай гына юк итә алмыйлар. Әмма, тырыша торгач, Болгарның башына барыбер җитәләр. Тукаебыз ни ди әле: «Мәгъмур болгар шәһәрләре, болгар авыллары бер дә булмаган төсле кырылдылар да беттеләр»,— ди. Болгарны монгол да талый, Аксак Тимер дә талый, ә 1431 елда рус князе Федор Болгар шәһәрен тәмам хәрабә хәленә китерә — таш өстендә таш калдырмый. Шуннан соң инде Болгар тернәкләнеп китә алмый, сүнә, бетә...

Кабер ташларыннан башланган сүз әллә кайларга алып кереп китте. Музейдан чыккач та балалар бер тын Йосыф Галиевич сөйләгәннәрдән арына алмый тордылар. Чокырчакырлы бу җирне күкрәп торган шәһәр итеп, җимерелгән таш пулатларны мәгърур сынлы биналар итеп күз алдына китерергә тырыштылар. Шушы урамнарда йөгереп йөргән болгар малайларын һәм кызларын күрәселәре килде аларның. Колакларына тупырдаган ат тоягы тавышлары ишетелгәндәй булды, кылычлар чыңгылдап китте, болгар малайлары һәм кызлары, кычкырышып, йорт араларына кереп югалдылар...

Болгар җиренә төн килде...

Балалар, Әнвәр Хаҗиевичка сыенып, кайтыр якка таба кузгалдылар. Алда, яктырып, инде авыллары да күренеп тора иде.

И Казан...

Ул төнне төне буе йоклый алмады Ногман. Беренчедән, карт галим сөйләгәннәр аңа тынгы бирмәде. Икенчедән, иртәгә алар Казанга баралар! Ногманның әле бер тапкыр да Казанны күргәне юк. Аның турында күпме җырлар ишетте, китаплардан күпме укыды, телевизордан көн саен тапшыруларын карый — ә үзендә булганы юк. Ногманны бигрәк тә сөендергәне — Казанга Зөлфия дә барачак. Зөлфия бар җирдә бигрәк рәхәт шул! Йөз, мең кеше булсын, Ногман Зөлфияне бер карауда күреп алыр иде. Аның күзләреннән, йөзеннән, чәчләреннән, кулларыннан әллә нинди якты бер нур таралып тора кебек. Ул нурның үз көе дә бар. Ул көйдән Ногманның яшеренеп кенә елыйсы да, сөенеченнән кычкырып-кычкырып көләсе дә килә...

Әнисе сак кына кагылуга, Ногман сикереп тә торды. Башта йоклап калганмын дип коты чыккан иде, урамга карау белән бераз тынычланды. Болгар өстендә әле таң беленеп кенә килә, агачларның яфракларыннан чык та кибек өлгермәгән. Әнисе һаман үзенең кинәшләрен бирә, зинһар, карап йөри күр, ди. Ә Ногманның күңеле күптән инде урамда, Зөлфияләр янында, самолетта, Казанда!!!

Аэропортта Ногман туп-туры балалар җыелып торган җиргә йөгерде. Инде килеп җитәм дигәндә, аяклары кинәт сөрлегеп туктап калдылар. Зөлфия янында иелә-бөгелә нидер сөйләнеп Руслан басып тора иде. Зөлфиясе дә көлгән була, кара толымнарын артка чөеп-чөеп җибәргән була. Ногманның күңелендә кайчаннан бирле яңгыраган нурлы көй тынып калды, ул башын иеп Йосыф абыйсы янына барып басты.

Менә зур ак самолет, аларның барысын да утыртып, Казан ягына таба күтәрелеп китте. Аста ачылган искиткеч күренештән Ногман Зөлфияне дә, Русланны да онытты, йөзе белән иллюминаторга капланды. Аста, зәңгәрләнеп, Идел елгасы күренеп калды, халык җырларына кергән кара урманнар тын гына артка чигенделәр. Аннан самолет, билгесезлеккә ташлангандай, ап-ак томан эченә чумды. Инде бу бушлыктан, бу билгесезлектән соң кайдадыр зур шәһәр булуы Ногман өчен ышана алмаслык хәл иде.

Ә шәһәр болытлар арасыннан һич көтмәгәндә килеп чыкты. Ул шулхәтле зур иде, шулкадәр еракларга сузылган иде — Ногман үзенә якынлашкан шәһәрдән күзләрен ала алмады. Беркем бер сүз әйтмәсә дә, бу шәһәрнең Казан икәнен аңлады ул.

Казан урамына аяк баскач та, ул башта югалып калды. Йөзләгән машиналары, туктаусыз йөреп торган кешеләре, бер-берсенә охшаган унар-унбишәр катлы йортлары белән Казан аны таң калдырды, куркытты. Үзе тонык кына туктаусыз гөжләп тора. Җилле көнне болгар урманнары шулай хәвефләнеп шаулыйлар. Кайда соң Болгардагы кебек манаралар? Кайда таш пулатлар, төрбәләр? Нигә гел бертөсле йортлар соң монда? Ногман Казанга бик җилкенеп, ашкынып килгән иде бит. Болгарда тапмаганнарын Казанда табармын дип уйлаган иде. Малай күзләре белән борынгылык чалымнарын, шәрык бизәкләрен эзләде, ләкин карашы таш йортлар арасында адашып калды. Аннан, курыкмый микән дигәндәй, Ногман сиздерми генә Зөлфиягә карап алды. Зөлфиянең күзләре зур булып ачылган, йөзе агарып киткән, үзе һаман Йосыф абый тирәсендәрәк йөрергә тырыша. Руслан-йомран инде Зөлфия турында онытып, сызгыра, башын чөеп, әй әллә кем булып барган була! Аның Казанга беренче генә килүе түгел шул. Ул биредә һәр җәйне була, аларның монда туганнары да яши бугай әле.

Ногман Зөлфия янынарак барып басты. Бу вакытта инде алар Кремль тирәсенә килеп җиткәннәр иде. Менә нинди икән ул Казанның атаклы Кремле! Әнә көн дә телевизордан күрсәтелә торган Спасс башнясы, сәгате дә нәкъ Мәскәү Кремлендәге кебек. Ә ничек яңгыратып, матур итеп суга!

Сәгать сукканын тыңлап торып, Ногман Йосыф абыйлары сөйләгәнен ишетмичә кала язган бит! Болай авызыңны ачып йөрсәң, бернәрсә белми кайтып та китәрсең! Ә мондагы биналар, истәлекле урыннар Болгардагы кебек санаулы гына түгел, күреп, ишетеп өлгерер өчен колагың сак, күзләрең үткен булу кирәк.

Кызыл кирпечтән салынган биек манара каршына килеп туктадылар. Йосыф абыйлары әйтә, атаклы Сөембикә манарасы менә шушы инде, ди. Шул! Ногманның әле бу манара рәсеме төшерелгән значогы да бар. Узган ел Зөлфия Казаннан алып кайтып биргән иде.

— Йосыф абый, нигә Сөембикә манарасы диләр соң аны?

Ногман биргән сорауга, әдәпсезләнеп, галимнән дә алда Руслан җавап бирергә ашыкты.

— Шуны да белмисеңмени? Моннан бит Сөембикә дигән хан сикереп төшеп үлгән. Шуна Сөембикә манарасы дип атаганнар.

Йосыф Галиевич ашыгып Русланга каршы төште:

— Сүзләрендә хата бар, Руслан, — диде ул җитди итеп. — Хәер, Казан тарихын, менә бу Кремльнең тарихын белми торып, сезнең күбегез, Руслан кебек үк, ул легендага ышанырга мөмкин. Ә тарихы аның менә болайрак булган. Мин моны кичә сөйләгән идем инде, тагы кабатлыйм. Аңлашылсын өчен, сүзне ерактанрак, тагы шул үзебезнең Болгардан башлыйм. Алтын Урда чорында экономикасы да, сәнгате дә чәчәк атып киткән Болгар иле XIV гасыр азакларына таба көчсезләнә башлый. Моның сәбәпчесе Алтын Урдага, шул исәптән аның составына кергән Болгар иленә дә туктаусыз һөҗүм ясап торган рус князьләре булалар. 1431 елда Федор Пестрый исемле князь Мәскәүдән килеп Болгар шәһәрен бөтенләй җимереп, яндырып

китә. Шуннан соң инде Болгар иле Болгар шәһәре тернәкләнеп китә алмый. Туктаусыз һөҗүм итүләрдән, янау-талаулардан тәмам алҗыган халык, гөлбакчадай җирләрен калдырып, әкренләп төньякка — Казан суы буйларына күченә башлый. Халык белән бергә аның культурасы, гореф-гадәтләре күчә, җыры-моңы күчә. Казан башта икенче урында — биек тау башында була, яшәргә җайсыз булганы өчен, аны бирегә күчерәлер. 1445 елда инде ул Казан ханлыгының башкаласына әйләнә. Менә хәзер без басып торган урында шушы дәүләтнең иң мөһим крепосте булган. Аның мәйданы 130 мең квадрат метрга хәтле җиткән. Крепость-Кремльнең стеналары нык имән бүрәнәләрдән бурап ясалган ныгытмалардан торган. Бүрәнә араларына таш һәм балчык тутырылган. Моннан тыш крепость тирәсе тирән ур-чокырлар белән дә әйләндереп алынган булган. Ул вакытта Кремль территориясендә ниндирәк биналар булган соң? Менә бу план-схемадан карамыйча, сезгә аларны күз алдына китерү авыррак булачак.

Йосыф Галиевич портфеленнән Казан Кремле территориясенең ул заманнардагы биләмәләрен чагылдырган зур план-схемасын чыгарды. Анда кара төртке булып укмашкан урыннарны күрсәтеп, сөйли башлады:

— Кремль ул вакытта төрле сарайлар, мәчетләр, төрбәләр, таш пулатлар шәһәрчеге булган. Ул архитектурасының кырыслыгы, мәгърурлыгы белән хәтта рус патшасы Иван Грозныйның үзен дә таң калдырган, хәвефләндергән. Менә биредә мәчетләр булган, һәр мәчет саен дүртәр-бишәр манара. Манаралар шул хәтле биек, төз булганнар, Казанга яу белән килүчеләр иң беренче аларны күреп шөбһәгә төшкәннәрдер. Ә менә монысы — хан сарае, каршысында — бакчасы. Ә менә болары — ханның якыннары, даирәсе, дин әһелләре яши торган сарайлар. Берничә төрбә, зур-зур мәдрәсәләр булган. Шушы тирәдә Сөембикәнең халык өчен салдырган бик бай китапханәсе дә булган, дигән фикерләр дә бар. Ләкин моны исбат итү хәзер кыен инде.

Балалар бер кәгазьдәге калага, бер күз алларындагы ак биналарга карадылар, нәни башларында гасырлар, ханлыклар, халыклар буталды. Ләкин кәгазьдәге кала кәгазьдә калды, бүгенге Кремль, бүген күргән Сөембикә манарасы, Казан символы булып, күңелләрендә урын алды.

Ногман да буталып урталыкта калган кебек булды. Ә менә бу биналар, бу манара, башнялар кайчан, ничек төзелгән соң? Болар бит барысы да ак таштан, кирпечтән. Кайсы гасырлардан калган истәлек соң бу Казан Кремле?

Тукта, менә монда, Кремль стенасына нидер язылган түгелме соң? «Кремль рус осталары тарафыннан салынган» дигәнме? Димәк, биредә болгар-татарлардан берни дә калмый, барысы да җимерелә, юк ителә, алар урынына ак таштан Казан Кремле салына? Ә Сөембикә манарасы? Җиде катлы Сөембикә манарасы?!

Ногман Зөлфиягә карап алды. Аның, ичмаса, апалары Казанда укый, әбисе бик гыйлем карчык. Сорарга кешесе бар.

— Зөлфия, кем соң ул Сөембикә?

Зөлфия Ногманга уйчан гына карап алды. Аннан, иелебрәк, пышылдады:

— Казан ханы бит. Соңгы ханы. Иван Грозный патша Казанга җитә башлагач, аны болай гына ала алмасын сизеп, хәйләгә керешә: «Сөембикәне бирсәгез, Казаныгызны алмыйм», — ди. Безнекеләр, шуңа ышанып, Сөембикәне бирәләр. Җиде яшьлек улы Үтәмешне, энисеннән аерып, чукындыралар, аңа Александр, дип исем бирәләр. Ул 21 яшьтә Мәскәү шәһәрендә үлә. Ә Сөембикәне Касыйм ханы Шаһгалигә бирәләр. Ул шунда тилмереп үлә...

— Ә Иван Грозный барыбер ала бит Казанны! Димәк, ул алдаган?

— Ул бик эшәке патша бит! Хәзер аны Сталинга, Гитлерга тиңләп язалар. Бер дә укымыйсыңмыни? Минем әби әйтә, ул, Казанга кергәч, җиде яшьтән җитмеш яшькәчә ир-атларның барысын да суйдырган, ди. Моны газетага да яздылар бит! Хатын-кызларны әсир иткәннәр, Казанда бер татар калдырмаганнар. Исән калган халык кара урманнарга чыгып качкан.

Йосыф абыйлары да шул турында сөйли икән. Җил аның тавышын таш пулатлар арасында бәргәләп йөртә.

— Казан ханлыгы белән рус дәүләте арасында туктаусыз феодаль бәрелешләр булып тора. Һәм 1552 елның октябрендә рус патшасы Иван Грозный үзенең гаскәрләре белән Казан каласын яулап ала. 1558 елдан инде Казан ханлыгына кергән бөтен җир биләмәләре рус дәүләте карамагына күчә. Казанны алу белән, бирегә күп кенә рус кешеләре күчеп утыра. Ә 1556 елның язында Казанга Псковтан 200 ташчы килә. Аларның башында атаклы рус төзүчеләре Постник Яковлев һәм Иван Ширяевлар булалар. Һәм менә сез хәзер күргән Казан Кремлен төзү башлана. Ак таштан Кремльнең стеналары һәм 13 башня төзелә. Ә менә бу Сөембикә манарасы исә шактый соңрак — 1645—1650 елларда, инде Казан ханлыгы җимерелүгә 100 елга якын вакыт үткәч төзелә, дигән сүзләр бар. Бу да

тарихи яктан исбатланмаган. Сөембикәнең манарадан сикереп төшүе дә легенда гына. Шушы тирәдә генә Сөембикәнең ире Сафа-Гәрәйнең мавзолей-каберлеге булган. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, Сөембикә һәр кичне шунда килеп яшь түгә торган булган. Хәзер инде ул чорларны, ул вакыйгаларны 400 еллык вакыт пәрдәсе каплаган. Кайда легенда, кайда чын, кайда хыял икәнен дә ачыклавы авыр, буталчык.

Кинәт, барысын да сискәндереп, яңгыратып, Кремль сәгате суга башлады. Астан гөжелдәп троллейбус үтеп китте. Әйе, бу инде XX гасыр, Казан каласын да меңгә төрләндергән XX гасыр иде.

Казан ханлыгы осталары

Кремль каршында гына Татарстанның Дәүләт музее бар. Тамак ялгап алганнан соң, Йосыф Галиевич балаларны шунда алып китте. Ул биредә Казан ханлыгы чорына караган бөтен табылдыкларны да белә, күбесен торгызуда үзе дә катнашкан галим иде. Шуңа күрә дә укучыларны туп-туры шул бүлеккә алып китте. Ләкин балалар аның сөйли башлавын да көтеп тормадылар, кызлар беләзек-чулпылар тирәсенә, малайлар таш-тимер кисәкләре янына барып басты.

Казан осталарының таш-тимер эшенә генә түгел, бик зур төгәллек һәм тәҗрибә таләп итә торган ювелирлык сәнгатенә дә куллары ятышлы булган,— дип сөйләп китте Йосыф Галиевич, тартмачыклар эчендәге алтын-көмеш бизәнү әйберләренә карап.— Менә бу нәфис алкалар, көмеш беләзекләр, алтын йөзекләр — барысы да Казан осталарының эше. Шунысы кызыклы — алар барысы да болгар осталары үрнәгендә эшләнгән. Бизәкләп эшләнгән көмеш төймәләр дә бик кызыклы. Мондый төймәләрне әле Казан татарларында XIX гасырның башында да күрергә мөмкин булган. Ә менә бу зур, йомры төймәләрне ирләр камзулына тага торган булганнар, алар төймәдән дә бигрәк киемдәге затлы бизәк ролен үтәгәннәр.

Йосыф Галиевич сөйләвеннән туктады да портфеленнән калын гына бер китап алды.

— Казан ювелирларының эше турында сөйләгәндә,— диде ул китапның бер битен ачып,— бик кызыклы бер хезмәткә туктамыйча ярамас. Ул «Казан бүреге» дип атала һәм ул Казан ханы өчен махсус ясалган булган. Хәзер аны бары тик Мәскәүдә, Оружейная палатада гына күрергә

мөмкин. Ләкин мин сезгә аның рәсемен күрсәтәм, бу таҗ турында, таҗдан да бигрәк, Казан ювелирларының гаять катлаулы һәм четерекле заказны нинди зур осталык белән башкарып чыгулары турында сөйләп китәргә уйлым.

Бу алтын таҗ XVI гасырның беренче яртысына карый. Алтыннан башта ярым түгәрәк форма коелган. Аның өстенә чокып матур нәфис үрнәкләр төшерелгән, алар махсус каралтылып, алтын белән аралашып бик матур чагылыш биргәннәр. Шушы формага нечкә алтын чыбыклардан яфрак кыяфәтендә үрелгән аерым кисәкләр беркетелгән. Яфрак уртасына төрле асылташлар — күк төседәй зәңгәр фирүзә, яшькелт зөбәрҗәт, кызгылт төстәге якут ташлар теззелгән. Таҗның аскы өлеше затлы мех белән әйләндереп алынган. Тик менә иң очындагы ахак кына соңыннан куелган дип исәпләнелә. Анда башта яки Казан гербы, я булмаса алтыннан ясалган ярым ай утыртылган булырга тиеш. Чөнки бу ахак таҗ бизәлешенең гомуми композициясенә туры килми.

Казан ювелирлары турында сүз чыккач, алар ясаган алтын каптырмалар турында да әйтеп китәргә кирәк. Тик алар да Казанда түгел, Ленинград, Мәскәү музейларында саклана. Күргәнегезчә, безнең күп тарихи истәлекләр читтә саклана. Алтын чыбыклардан нәни чәчәкләр үрелгән һәм алар алдан кысасы кисеп куелган зур чәчәкләр эченә урнаштырылган. Хан таҗы кебек үк, бу каптырмалар да төрле асылташлар белән бизәлгән. Мондый алтын каптырмалы каешларны бары тик ханнар һәм зур байлар гына йөрткәннәр.

Әле алтын таҗ, каптырмалар турында сөйләгәндә бераз кызыграк кебек тоелса да, балалар төркеме балчык савытлар ягына борылгач, Русланның эче поша башлады. Ул иптәшләреннән аерылды да бәрелә-сугыла музей буйлап берүзе китеп барды. Кителеп беткән балчык чүлмәкләр карар өчен килмәгән лә ул Казанга!

Ә балалар кызыксынып моннан 400 ел элек ясалган әй-

берләрне күзәтә башладылар. Әнә киштәләрдә ухылдашып йомры чүлмәкләр, тар муенлы кувшиннар, җиз комганнар утыра. Алар болгар чоры савыт-сабаларына бик охшаганнар. Әнә кайбер савытларның борыны әтәч башына охшатып ясалган — Болгарда мондый савытлар очраган иде инде. Якты ачык җирлеккә зәңгәрсу һәм яшькелт төстәге бизәкләр төшерелгән. Бу бизәкләр, тасма-тасма булып, савытларны әйләндереп алганнар. Ләкин Казан чүлмәкчеләре өчен төс яки бизәк түгел, савытларның матур һәм уңайлы формасы мөһимрәк булган, күрәсең. Һәм алар шуңа ирешергә тырышканнар да. Алар эшләгән савыт-сабаны руслар да, башка милләт халыклары да яратып кулланган, һәм бу төр әйберләргә сорау бик зур булган. Йосыф абыйлары шул турыда сөйләде.

Чүлмәкләрдән соң, Казан ханлыгы чорына караган экспонатлар бетте. Күргәннәргә нәтиҗә ясарга теләгәндәй, Йосыф Галиевич укучыларны үз тирәсенә җыеп алды.

— Сез күргәннәр — Казан ханлыгы чорыннан сакланып калган сәнгать әсәрләренең бик кечкенә бер өлеше генә ул. Казан да заманында бик зур җимерелүләргә һәм яндыруларга дучар булган. Халык тарафыннан тудырылган байлык — сәнгать әсәрләре дә дөнья буйлап таралган, юкка чыккан. Ләкин халык бар җирдә яңа осталар үсеп чыга, яңа талантлар ачыла. Менә XVIII—XIX гасырларның тарихын өйрәнгәндә, сез аның шулай икәнен үзегез үк күрерсез.

Шушы икән! Казан шушы икән! Бәрхет тартмаларда бер-ике көмеш беләзек һәм каптырма — ул борынгы Казан икән! Болгардагы кебек, кабер ташлары да юк икән! Манаралар да юк икән. Казан әллә нинди икән...

Шаулашмый гына, әкрен генә музейдан чыгып киттеләр. Ә урамда, берни булмагандай, һаман машиналар чабулый, кешеләр каядыр ашыга, һаман яңгыратып Кремль сәгате суга. Музейдагы кебек, монда вакыт та, тормыш та туктап калмаган, һаман үз юлыннан дәвам итә...

Әнвәр Хаҗиевич балаларны саный-барлый башлагач, кына, араларында Руслан булмаганлыгы беленде. Инде кабат музейга кереп тә эзләп карадылар — таба алмадылар. Беркемгә берни әйтми, Руслан юкка чыккан иде.

Иске йорт янында

Русланны Казанга алып барырга башта ук күбесе каршы торган иде. Йосыф Галиевич кенә яклап чыкты үзен — фән өчен бик кыйммәтле хәзинә тапкан иде шул теге вакытта Руслан.

Алып килүен килделәр, күз алдында юкка чыгуын белгәч, барысы да аптырашып-куркышып калдылар. Кая китәргә мөмкин икән ул мондый зур, билгесез шәһәрдә? Әгәр адашкан булса? Хәзер берьялгызы аларны табалмый шәһәр буйлап тилмереп йөрсә? Тик Зөлфия сүзләреннән соң гына бераз тынычлангандай булдылар.

— Аларның Казанда туганнары бар,— диде ул тизрәк Әнвәр Хаҗиевичны тынычландырырга теләп.— Яңа бистәдә торалар.

Әнвәр Хаҗиевич ашыгып Зөлфия янына килде.

— Ә син аларның адресын белмисеңме, Зөлфия?

— Юк шул. Узган ел, Казанга килгәч, әни белән бер кереп кенә чыккан идек.

Йосыф Галиевич тә Зөлфия янына килде.

— Бәлки, аларга бара беләсеңдер, Зөлфия? Хәтереңдә калгандыр, бәлки, ул йорт?

Анысы, хәтерләвен бераз хәтерли Зөлфия. Бик сәер йорт иде ул. Андый йортлар әкиятләрдә һәм тарихи китапларда гына калгандыр инде. Тик менә ул тирәдәге күп йортларны сүтәләр иде. Бәлки, ул йортны да сүткәннәрдер?

— Әгәр бик арымаган булсаң, без хәзер синең белән шунда китәрбез,— диде Йосыф Галиевич.— Арыган булсаң да бармый ярамый, сеңлем. Русланны анда тапмасак, милициягә хәбәр итәрбез.

Әнвәр Хаҗиевич балалар белән кунакханәгә кайта торырга булды. Тик Ногман гына алар төркеменә иярмәде, уңайсызланып кына Йосыф Галиевич янына килеп басты.

— Мин дә сезнең белән барыйм әле, Йосыф абый?

— Ярый, Ногман,— дип риза булды галим.— Әйдә безнең белән. Бәлки, берәр ярдәмең тияр.

Көннең эссесе әле сүрелмәгән иде. Бу эсселектән хәтта аяк астындагы асфальт йомшарган, баскан саен, тибрәнеп-тибрәнеп куя. Йосыф Галиевич алдан атлый, аның артыннан, бер адым да калмаска тырышып, Ногман белән Зөлфия бара. Аннан трамвайга утырып шактый бардылар, аннан тагы җәяү киттеләр. Хәзер инде алдан Зөлфия, аның артыннан Йосыф Галиевич белән Ногман килә иде.

Зөлфия гаҗәпләнеп як-ягына каранды. Элек, бу тукталышта трамвайдан төшүгә, агач өйләр башлана иде. Ә хәзер әнә каршыга тугызар катлы таш йортлар чыгып басты. Алар аша бистә урамы күренми дә.

Йортларны әйләнеп үттеләр. Биек-биек коймаларга барып төртелделәр — аларның теге ягында да төзелеш бара иде.

Могҗиза белән сакланып калган бер колонка янына туктап, су эчтеләр, бит-кулларын юдылар. Чү, бу колонканы хәтерли бит Зөлфия. Узган ел, хуҗа кызына ияреп, шушында суга килгәннәр иде бит! Юл буе сөйли-сөйли килгән иде ул кыз — кайсы йортта кем яши, кайсы йортның малайлары усал да кайсы йортның кызлары аның белән дус.

Хәтерендәге менә шул йортлар буйлап туп-туры китте Зөлфия. Яшь хәтер алдамады — берничә минуттан инде алар шактый бөкрәйгән, ләкин әле, бирешергә теләмәгәндәй, тәкәббер генә кукраеп утырган бер йорт каршына килеп чыктылар. Русланның туганнары шушында яши иде.

Ләкин алар монда Русланны очратмадылар. Өйдә карт белән карчык кына булып, шикләнә-шикләнә генә җавап бирделәр дә, ишекне бикләп тә куйдылар.

Русланны бераз вакыт урамда көтеп карарга булдылар. Чөнки аның Казанда башка барыр урыны юк, ул барыбер бирегә кайтачак иде.

Капка төбендәге кечкенә генә эскәмиягә килеп утырдылар. Көне буе аяк өстендә йөргәннән соң, күләгәдәге бу утыргыч та җан рәхәтлеге бирә иде. Ә Йосыф Галиевич һаман йортны күзәтә икән. Кулларын артка куеп, тирәюненнән бер әйләнеп тә килде. Капка баганаларын тотып карады, койма янына килеп нәрсәнедер җентекләп күзәтте, үреләүрелә тәрәзәләргә карады. Тәрәзә кырыеннан күзәтеп торган әби ашыгып читкә тайпылды, бу ак чәчле ир-атның нишләп йөрүен аңлый алмады ул.

Ә Йосыф Галиевич, инде Руслан турында да онытып, йортның архитектурасын, бизәлешен өйрәнә иде. Аннан, эскәмиягә утырып, куен дәфтәренә тиз-тиз нидер язып та куйды.

— Йосыф абый, берәр яңалык таптыгызмы әллә? — дип сорады Ногман кызыксынып.

— Яңалык та түгел инде ул, балалар,— диде галим аларга якынрак утырып.— Мондый йортлар — XVIII гасырның ахырына, XIX гасырның башына хас күренеш. Ләкин инде алар күптән җимерелеп бетеп, төрле алымнарны төрле йортларда гына очратырга туры килгәли иде. Ә менә бу йортта ул чор архитектурасының бөтен үзенчәлекләре сакланган.

— Бу шул вакыттан калган йортмыни? — дип сорады Зөлфия дә өйгә борылып карый-карый.

— Юк, бу йорт XX гасыр башларында салынган булырга тиеш,— диде Йосыф Галиевич.— Ләкин анда элекке гасыр йортларының төзелеш формасы, бизәкләре бик төгәл күчерелгән. Патша самодержавиесе, рус халкын җәберлә-



гэн кебек, татарларны да бик нык кысрыклаган бит. Казан ханлыгы бетерелгәннән соң, татарлар урман эчендәге авыл-ларга, Кабан күле буендагы сазлык урыннарга, менә шушы тирәләргә күчеп утырганнар. Аларга күп еллар буе монументаль биналар, таш йортлар салырга рөхсәт ителмәгән. Менә шул чорда инде агач йортлар архитектурасы, аларның бизәлеше бик нык үсеш ала. Йортларны урамнан шактый эчкә кертеп салалар. Мондый күренеш болгар чоры йортларына да хас. Йорт биек койма белән әйләндереп алына, ишегалдына «урыс» капка аша гына үтеп керергә мөмкин була. Койма да, капка да бизәкләп эшләнә, йортларның исә тәрәзә кашагалары, кәрниз аслары матурлап бизәлә. Ул чорның балта осталары күпләр таң калырлык йортлар торгыза торган булганнар. Бигрәк тә Казанга килеп чыккан чит мәмләкәт кешеләре агачтан шундый зур осталык белән бизәкләп салынган татар өйләрен күреп бик гаҗәпләнгәннәр. Мондый бер катлы йортлардан тыш, хәллерәк кешеләр икешәр катлы өйләр дә салдырган. Ике катлы

йортларның күбесе балконлап, верандалап эшләнгән, икенче катның өстендә тагы бер тәрәзә — чарлак тәрәзәсе булган. Анда гадәттә хуҗаның кыз балалары торган.

Ногман да, урыныннан торып, капкадагы каралып-муртаеп беткән бизәкләрне тотып карады. Чыннан да, яңа чакта бик матур булгандыр бу бизәкләр. Әллә нинди түгәрәкләр, алардан тирә-юньгә юл-юл нурлар киткән. Аннан ярым кояш формасындагы бизәкләр, буй-буй юллар. Ләкин алар инде шулкадәр искергәннәр, саксызрак кагылсаң да, җимерелеп төшәрләр кебек.

— Болгар кабер ташларын хәтерлисезме? — диде галим, дәрес биргән кебек.— Аларда да шушындый бизәкләр бар иде бит. Сезгә әле тәрәзә кашагалары ачык күренмидер. Аларга бигрәк тә мәгънәле бизәкләр төшерелә торган булган. Әйтик, төрле кошлар, пар үрдәк, мәче башлы ябалак, ярканат сурәтләре еш очрый. Алар аерым такталардан төгәл генә киселеп, вак кадаклар белән бизәләсе урынга беркетелгәннәр. Оста кулында гади балта да могҗиза тудырган, гасырлар буе яши алырлык матурлык калдырган.

Йосыф Галиевич шул хәтле онытылып, бирелеп сөйли иде, чаттан Русланның килеп чыгуын сизми дә калдылар. Аларны күргәч, Руслан егылып китә язды. Болгарда шушы сүз, музейда шушы сүз, инде җәһәннәмдәге йортны эзләп табып, шуның капкасына карап, нәрсә сөйләргә мөмкин икән?! Әллә әзрәк җиңеләя башладылар микән соң болар?

Менә бер мәлне барысы да Руслан ягына борылып карадылар. Русланның ике кулында ике морожный, җилкә аша асылган сеткасыннан банка-банка варенье күренеп тора иде. Һәммәсенең дә үзенә сүзсез генә карап торуын күргәч, ул аклана башлады.

— Менә, әни кучтәнәч илтергә кушкан иде бабайларга. Менә, шуны китердем...

— Әйтеп китәргә кирәк иде аны, Руслан.— Йосыф Галиевич аңа кырыс кына карап куйды.— Бар кертеп чык инде кучтәнәчеңне.

Руслан йөгереп өйгә кереп китте. Күп тә үтмәде, тәрәзәдән башын чыгарып, аларга кычкырды:

— Әйдәгез, өйгә керегез. Сезне бабай чакыра.

Йосыф Галиевич, гаҗәпләнеп, балаларга карады. Башта сөйләшәселәре дә килмәгән иде хуҗаларның, хәзер нишләп өйгә үк чакыралар икән? Шулай да, кереп чыгарга булдылар. Бәлки, йортның эчендә дә заман калдырган берәр бизәк бардыр?

Сандык малы

Әби белән бабай тәрәзә аша галим сөйләгәнен тыңлап торганнар икән. Бабайның күзләре үк яшьләнгән, чөнки бу йортны аның әтисе үз куллары белән салган булган. Бабай әле ул чакта менә шушы Ногманнар кебек малай булган, алдан кисеп куйган бизәкләрне атасына үз кулы белән биреп торган. Менә бу кеше, суга караган кебек, бөтенесен дөп-дөрес итеп сөйләде дә бирде. Ничек шундый галим затны өйгә чакырмыйсың ди?

Чәй янында да сүз күбрәк йорт турында барды. Йосыф Галиевичнең хуҗа әби белән дә сөйләшеп карыйсы килгән иде, ләкин ул нигәдер гел почмак якта кайнашты. Ашыга-ашыга кадерле кунакка төче коймак пешереп ята икән. Алар сөйләшеп утырган арада, тәлинкәгә түбәләмә өелгән коймакларын күтәреп, чыгып та җитте. Әдәп белән генә кыстый-кыстый сыйлый да башлады.

Йосыф Галиевич һаман өй эчен күзәтте. Юк, ул заманнардан калган чиккән сөлгеләр дә, чаршаулар да күренми инде йорт эчендә. Тәрәзәләрдә — заманча озын пәрдәләр, диван-караватларда атлас япмалар. Бер почмакта өелеп торган тау-тау мендәр генә бу йортта татар гаиләсе яшәгәнлеген сөйли. Мондый мендәрләр, ястык-түшәкләр — болгар чорына ук хас урын-җир әйберләре.

Галимнең мендәрләр ягына карап-карап алуын күреп, әби сорап куйды:

— Мендәрләр турында да берәр сүзең бармы әллә, укымышлы бәндә?

— Мендәрләр турында юк югын. Мендәрләр үз урынында. Менә сөлгеләр сакланмадымы икән сездә? Йорт урыныгыз шактый борынгы күренә, мондый йортның үз гореф-гадәтләре, буыннан-буынга тапшырыла торган сандык малы да була.

Сандык малы диюгә, әби бабайга карап куйды. Бабай, ризалык белдергәндәй, тамак кырып алды. Шуннан соң гына әби урыныннан кузгалды, түрдә торган зур агач сандыгын иплән кенә ачты да берәм-берәм аннан әйберләрне бушата башлады. Һәм иң астан кечкенә бер төргәкне алды да чишеп җибәрде. Төргәктә бик нәфис үрнәкләр белән чигелгән сөлге икән. Әби аны саклык белән генә тотып галим каршына алып килде.

— Мәрхүм әнидән калган сөлге инде бу. Кыз чагында бирнәгә әзерләгән булган.

Йосыф Галиевич сөлгенең кыйммәтлелегенә шундук төшенде. Юк, баш-башлары алтын җепләр белән чигелүдә

генә түгел иде аның кадере. **«Казан сөлге»**ләре, гомумән, алтын җептән, бик зур зәвык белән чигелгәннәр. Монда хикмәт башкада — аның гадәти булмаган үрнәгендә иде. «Казан сөлге»ләренең күбесенә мул итеп чәчәк бизәкләре чигү хас. Ә бу сөлгегә әнә кара-каршы утырган ике кош сурәте төшерелгән. Араларында — биек тау.

Ярдәмгә әби үзе килде.

— Сак-Сок бәетендәге Сак белән Сок кошлары болар,— диде ул бизәкләрне әкрен генә сыйпап.— Мәрхүм әни без кечкенә вакытта гел әйтә иде шул бәетне.

Йосыф Галиевичнең Сак-Сок бәетен ишеткәне булса да, балалар белмиләр икән. Сөйлә дә сөйлә дип, әбигә ялына башладылар.

— Бәетне сөйләп булмый инде аны, оланнар,— диде әби йомшак кына.— Бәетне аны әйтәләр генә.

Йосыф Галиевич тә бик ялынып сорагач, әби, авыз кырыен яулык белән каплабрак, бер читкә карап, әкрен генә тавыш белән бәет әйтә башлады. Әбинең тавышы шул хәтле моңлы иде, бәетнең сүзләре шул кадәр тетрәндергеч иде, балалар гына түгел, өлкән галим үзе дә сүзсез калып, башларын иделәр. Күз алларына тимер ук өчен пыр тузып сугышкан ике малай килеп басты. Алар шундый нык якалаша, үзләренә кат-кат эндәшкән әниләренең тавышын да ишетмиләр. Әйтеп-әйтеп тә тыңлата алмагач, әниләре сәкегә утыра да елый-елый аларны каргарга тотына. Шул чак ике малай кошка әйләнә дә икесе ике тәрәзәдән очып чыгып та китә. Оча-оча кара урманнар үтәләр, күп газаплар күрәләр, биек тауның икесе ике ягында аерылып калалар. Төне буе икесе ике яктан тау башына күтәреләләр, кавышабыз дигәндә генә, тагы таң ата. Һәм алар тагы кош кыяфәтендә калалар, берсе «сак» дип, икенчесе «сок» дип кычкырып, гомер буе тауның икесе ике ягында утыра...

Әби бәетне әйтеп бетерде. Сөлге башына чигелгән Сак-Сок кошларының моңлы тавышы балалар җанына да барып бәрелде. Ләкин иң нык тәэсирләнгәне Руслан иде. Күз алдына кечкенә генә буйлы әнисе килеп басты. Шул тыңламавы, кирелеге белән ул да әнисен әзме җәзалады? Уты-

рып-утырып елый иде бит аның әнисе дә. Русланның тизрәк Болгарга, әнисе янына кайтасы, барысы өчен дә аннан гафу үтенәсе, аңа яхшылык эшлисе, сөендерәсе килде.

— Йосыф абый, без кайчан өйгә кайтабыз инде? — дип сорады ул әкрен генә.

Зөлфия белән Ногман да нәкъ шуны уйлап утыралар икән. Алар да, ни әйтер икән дип, Йосыф абыйларына текәлделәр.

— Кайтырбыз, балалар, кайтырбыз,— диде ул аларның моңаеп калган йөзләрен күреп.— Иртәгә менә Кырлай якларына барабыз. Ә Кырлайдан соң — яңадан Болгарга.

Әби белән бабайга зур рәхмәтләр әйтеп, кайтырга кузгалдылар. Сак-Сок бәетеннән соң нинди дә булса сүз кузгату мөмкин түгел иде. Үзендә бик күп хатирәләр саклаган агач өй, ачык тәрәзә янына баскан әби белән бабай, тарихның үзе кебек, аларны тын гына озатып калдылар.

Кырлай яклары

Таң белән Кырлайга җыена башладылар. Йосыф Галиевич кайдандыр автобус белешеп куйган, шул җыйнак кына автобуска төялешеп, әле яңа йокыдан уянып килгән шәһәрне артта калдырып, мәшһүр «Казан арты»на юл тоттылар.

Юл өстендә эреле-ваклы авыллар калды, нурга, ямьгә төренеп утырган урманнар озата барды, яшел болыннарда тыныч кына утлап йөргән көтү-көтү маллар очрады. Болгар балаларына болар барысы да бераз яңа да, шул ук вакытта бераз таныш та кебек иде. Алар ягында да менә шушындый ук авыллар, авыл башларында шаулап утырган зиратлар бар бит. Тик биредә яшеллек, урманнар-таулар күбрәк ахры. Болгар җире исә тип-тигез дала да кыр, дала да кыр...

Сул якта биек тау күренде. Ул тау балалар моңа хәтле күргән барлык таулардан да биегрәк булып тоелды. Йосыф абыйлары: «Иске Казан шушы була инде»,— диюгә, барысы да тәрәзәгә капланды. Иске Казан! Менә нинди биек тау башында булган икәнсең син! Сиңа дошман килә алмагандыр, үз халкың өчен дә яшәү җиңел булмагандыр. Әнә бит, Йосыф абый әйтә, бер хатын, түбәнгә, Казан елгасына су алырга төшкәч, менгәндә бик сукранган, ди, «Нинди хан мондый җайсыз урынга кала сала инде!» — дип әйткән ди. Халык зарын ишетеп, хан Казан каласын башка урынга, ягъни, хәзерге урынына күчергән, ди. Кара, ханнар да халык белән санлаштылармы икәнни?



Йосыф Галиевич юл буе сөйләп барды. Авыллар аша үткәндә бик матур итеп бизәлгән йортларны күрделәр — аларның челтәрле-челтәрле, ак, зәңгәр төсләргә буялган тәрәзә кашагалары әллә кайдан балкып тора иде. Тәрәзә төпләрендә шау чәчәкле кына, яран гөлләре, капка төпләрендә бала-чага мәш килә. Һәр капкага терәп диярлек машина-мотоцикл өчен гараж салып куелган.

— Заман сәнгатьнең һәр төренә, шул исәптән архитектурага да үз үзгәрешләрен кертә,— диде Йосыф Галиевич тәрәзәдән карап.— Әле узган гасырда гына кирәклеге бәхәссез булган күп корылмаларның — әвеслек, ашлык амбары, салам түбәле лапасларның инде эзе дә юк. Алар урынына әнә йортлар тирәсендә верандалар, матур рәшәткәле ян бакчалар, шифер түбәле каралты-кура галереясы калкып чыккан. Ә өйләрнең үзләре сырлап-челтәрләп аллыгөлле төсләргә буялган — экият дөньясымыни. Бу як халкы бик тырыш, зиһенле халык. Элек-электән Казан арты үзенең осталары белән данлыклы булган. Биредә читекчеләр дә, итекчеләр дә, чигүчеләр дә, тегүчеләр дә, тукучылар да, киезче-келәмчеләр дә, алтын-көмештән бизәнү әйберләре коючылар да, бакырчылар да, дугачылар да, кабер ташларын бизәүчеләр һәм искиткеч матур хәрефләр белән китап күчерүчеләр дә булган. Мондагы халык һәр нәрсәне үз кулы белән эшләргә өйрәнгән. Казан арты халкы элек-электән эшкә дә оста булган, гыйлемлегә ягыннан бу яклар якты бер төбәк булып дөньяга зур шәхесләр биргән.

— Тукай,— диде кинәт юл буе бер сүз эндәшмәгән Руслан. Барысы да гаҗәпләнеп аңа борылып карадылар.

— Әйе,— диде Йосыф Галиевич,— бер Тукае өчен генә дә Казан артына татар халкы мәңге рәхмәтле.

— Я, Казан артында тагы нинди зур шәхесләр, язучылар туып-үскән? — дип сорады Әнвәр Хаҗиевич, нәкъ дәрес вакытындагы кебек.

Башта барысы да тынып калдылар. Аннан Зөлфия кыяр-кыймас кына:

— Сибгат Хәким,— диде,— чөнки ул бу шагыйрьнең җырларын бик ярата иде, аларда еш очраган «Казан арты», «Кырлай яклары» дигән сүзләрдән әллә нинди серле бер дөньяны күз алдына китерә иде.

Анда ул,
Анда ул утларның
Тукайлар яшьлектә якканы.
Кайда да йөрәктә, йөрәктә,
Төшләргә кереп гел йөдәтә
Нигә соң,
Нигә соң бу Кырлай яклары?

— Дөрес әйттең, Зөлфия,— диде Әнвәр Хаҗиевич.— Сибгат Хәким нәкъ шушы якларда туып-үскән зур шагыйрь. Бүгенге көн язучыларыннан тагы Гомәр Бәширов, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Рафаил Төхфәтуллин, ераграк чорларны алсак — халкыбызның зур тарихчысы Шиһаб Мәрҗани, шагыйрь һәм галим Габделнасыйр Курсави, гыйлем ияләре Шәмсетдин Күлтәси, Гали Мәхмүдов, күренекле драматург Галиәсгар Камал, Хәсән Габәши, композитор Солтан Габәши — шушы як кешеләре. Тикмәгә генә Казан артын ак як димиләр шул.

Әнвәр Хаҗиевичның сөйләгәнен галим дә бик нык игътибар белән тыңлап барды. Ара-тирә юл өстендә очраган авылларга, шул авыл урамнарында дөньяларын онытып уйнап йөргән кара чәчле малайларга карап алды. Шушы малайлардан яңа Тукайлар, яңа Сибгатләр үсеп чыкмас дип кем әйтә ала? Болгарларның бөтен осталыгын, гыйлемен, зиһенен канына сеңдергән халык бит ул. Тукай үзе үк әйткәнчә: «...халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул».

Бер авылга су эчәргә туктадылар. Кешеләрдән сорашып, чишмәнең кайда икәнен белделәр дә, авыл урамы буйлап шул якка йөгерделәр. Йосыф Галиевич алар артыннан чак өлгерде һәм елмаеп уйлап барды: «Балалар кайда да балалар инде. Йөгерергә урам булсын, чишмә булсын, ирек булсын...»

Чишмә тау астында булып, вак кына ташлар арасыннан тибеп чыга иде. Өстен җыйнак кына итеп буралап та

алганнар, су агып чыга торган урынга улак ясаганнар. Балалар шул улак тирәсен сырып алдылар. Кайсы боздай салкын су белән битен-кулын юды, кайсы учларына алып, иреннәренә тидерде. Шул чак кинәт ат пошкырган аваз ишетелде. Барысы да гаҗәпләнеп, башларын күтәреп карадылар. Каршыларында әкиятләрдә сөйләнә торган ап-ак ат, аның өстендә алар яшендәге ак күлмәкле бер малай утыра иде. Ул таныш түгел балаларга, болгар балалары исә тарихның үзеннән килеп чыккандай тоелган бу кара күзле малайга карашып тордылар.

— Ат эчерергә килдеңмени, энем? — дип сорады Йосыф Галиевич. Малай өстән карап горур гына җавап бирде:

— Юк. Чабыш алдыннан атка мондый салкын су эчермиләр. Аягына төшә.

— Әле чабыш атымыни бу? Кара син аны нинди матур!

— Атның өстенә карап алай әйтмиләр. Күз тиюе бар.

Малай атын кырт кына борды да, каерылып карый-карый, балалар ягына кычкырды:

— Менә иртәгә Сабан туенда күрерсез әле. Минем Чаткы ел да беренче килә.

— Менә Казан арты малайлары нинди алар,— диде Әнвәр Хаҗиевич көлеп.— Ут! Шәп ир-егетләр үсәр алардан!

Кара, иртәгә Сабан туе икән бит! Барысының да исенә тагы болгар яклары, Рабига күле буенда үтә торган Сабан туйлары, шулар аша елмаеп карап торучы әниләре төште. Балаларның бераз моңсуланып калуын күргәч, Йосыф Галиевич сүзне тагы атлар турында башлап китте. Автобуска утырып, чишмәле авыл еракта калгач та, сүз атлар турында бара иде әле.

— Атлар — татар халкының иң борынгы тугры юлдашы,— диде Йосыф Галиевич.— Ул ауга да, яуга да атка атланып барган, үзләре белән бергә атлары да ауган, аумаганнары тагы йөзәр-меңәр чакрым юл үткән. Күп вакыт бөтен ышаныч атта, аның чыдамлыгында, сизгерлегендә булган. Һәм ул кешеләрне беркайчан да авыр хәлдә калдырмаган.

Эш аты, чабыш аты, сугыш атлары турында сөйләшеп алдылар. Ләкин нинди генә урында булмасын — кеше дә атны бик саклаган, кадерләгән. Һәм кулыннан килгәнчә аны бизәргә, матурларга тырышкан.

— Мин сүз башында бу якта дугачылар да булуын әйткән идем бит,— диде Йосыф Галиевич.— Биредә атлар өчен данлыклы «татар дугалары» эшләгәннәр. Ул ак, зәңгәр, кызыл яки ак, зәңгәр, яшел төсләр белән чиратлаштырып буяла торган булган. Дугаларга җиз кыңгыраулар таккан-

нар. Туй вакытларында ул дугалар чиккән, суккан сөлгеләр, кулъяулыклар белән бизәлгән.

XIX гасырның ахырында XX гасырның башында Казан тарантаслары да бөтен Россиягә билгеле булган. Бу тарантаслар шулай ук Казан арты осталары тарафыннан эшләнгән. Ул кызыл, зәңгәр, ак, сары, яшел төсләргә буялган тал чыбыкларыннан үрелгән һәм алар, чиратлашып, бик матур үрнәкләр хасил иткәннәр. Бу тарантасларны чит өлкәләрдә дә күпләп сатып ала торган булганнар. Хәзер бу һөнәрләрнең күбесе юкка чыкты инде.

— Йосыф абый, ул заманнардан калган берәр һөнәр бүген дә дәвам итәме соң? — дип сорап куйды Ногман.

— Бар, әлбәттә. Балта осталарының эшен менә үзегез күрдегез. Кайбер авылларда, бигрәк тә Саба якларында, көмешчеләр дә бар әле. Ләкин иң билгесе... Я, кайсыгыз белә, Арча яклары бүгенгесе көндә тагын нәрсәсе белән дан тота?

Зөлфия, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән әйтеп куйды:

— Читекләре белән.

Зөлфиянең апасы узган ел беренче хезмәт хакына Казанга барып әнисенә чиккән читекләр алып кайткан иде. Ул читекләрнең матурлыгына, анда төшерелгән яфрак-чәчкә бизәкләренең пөхтәлегенә, нәфислегенә таң калганнар иде. Шунда апасы бу йомшак читекләрнең Арчада тегелгәнен әйткән иде.

Зөлфиянең уйларын Йосыф Галиевич сүзләре бүлде.

— Әйе, Арча яклары элек-электән үзенең читекләре белән данлыклы. XVIII гасырда бу як хатын-кызлары башта аларны үзләренә бирнәгә чиккәннәр. Соңыннан, чиккән читек-туфлиләргә сорау зур булгач, күпләп тә эшли башлаганнар. Аларны Башкортстанга, Себергә, Идел буе шәһәрләренә, Урта Азиягә озатканнар. Чиккән читекләр Көнбатыш Европа илләренә дә барып җиткән. 1934 елда Арча районының Клачы авылына Германиядән махсус делегация килеп төшә. Алар бизәкле читекләр тегә торган машинаны карарга, өйрәнергә һәм аннары шундый машина ярдәмендә үзләрендә дә читек тегә башларга уйлаганнар. Әмма бизәкләрнең кул белән тегелгәнен күргәч, немец белгечләренең гаҗәпләнүләре чиксез була. Һәм алар, мондый читекләрне машина белән тегеп булмый икән, дигән карарга киләләр.

Читек тегү — шактый катлаулы һәм авыр хезмәт. Читеккә дигән күнне, чәчәкле бизәкләрне кисү — ирләр эше булган, аларны бер рәвешкә салып тегүне һәм бизәкләп чигүне хатын-кызлар башкарган. Бүгенгесе көндә дә бу читек-

ләрне тегәләр, һәм аларны күп милләт хатын-кызлары бик яратып кия.

Алда гөжләп утырган урман күренде. Мондагы агачлар шулкадәр юан һәм биекләр иде, юл буенда шулкадәр тантаналы шомлык саклап басып торалар иде, ирексездән балалар тынып калдылар. Күңелгә тагы Тукай килде, «Һәр ягы урман» булган Кырлай авылы килде.

Бераздан авыл үзе дә күренде. Автобус белән Габдулла Тукай музее каршына килеп туктадылар. Йорт каршындагы эскәмиягә Тукай үзе утырган. Кырыенда урман шүрәлеләре биешә. Тукай, көлемсерәп, аларга карап тора. Юк, ул аларга гына карамаган икән — карашы әнә балаларга да төште. «Мин сезне күптән көттем инде»,— дигән кебек аларга карап тора. Шул чагында әллә күрше йорттан, әллә музейның үзеннән бик моңлы бер көй ишетелде...

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Хәйран булып, җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Һәм менә бүген болгар балалары үзләре Тукай каршына килеп бастылар. Тарих сәхифәләреннән мең еллык юл үтеп, халыкның мең шатлык һәм мең хәсрәтен белеп, алар менә бирегә килеп җиттеләр. Алар мәңгелек хәзинә — сәнгать дөньясы хәзинәләрен эзләүчеләр. Эзләп табып, бөртекләп, кадерләп, киләчәккә дә илтеп җиткерүчеләр.

Тукайның аяк очына Болгардан алып килгән бер уч туфракны салдылар. Музейда булып чыкканннан соң, кечкенә Габдулла йөгереп йөргән авыл урамнары буйлап үттеләр, мәктәпкә барып, укучы балалар белән очраштылар, аларга Болгар турында сөйләделәр һәм үзләренә кунакка чакырдылар.

* * *

— Син үскәч кем булырга уйлыйсың? — дип сорады Зөлфия янәшәсендә утырган Ногманнан. Алар инде карурманнар өстеннән кире Болгарга очалар иде.

— Минем... ак пулатлар төзисем килә,— диде Ногман, үзе, аңлармы икән, дигәндәй, уңайсызланып Зөлфиягә карады.— Минем башы күккә ашкан манаралар торгызасым килә. Шәһре Болгарның данын кабат шаулатасым килә. Казан да кызганыч...

— Әйе шул,— диде Зөлфия.— Җимерек булса да, безнең Болгар матуррак. Болгар серле, сихерле ул. Мин бит биредә тудым. Әби әйтә, безнең нәсел бу җирдә мең ел яши инде, ди. Бик укымышлы, затлы нәсел иде, ди...

Ногман, үзе дә сизмәстән, Зөлфиянең кулын үз кулына алды. Кызның озын ак бармаклары дерелди иде. Юк, ни әйтсәң дә, гади кыз түгел бу Зөлфия. Хан нәселеннән булуы да хактыр аның. Кем генә булса да, Ногман аны мәңге саклаячак, аңа атап, ак таш пулатлар салачак, аның исеменә атап, манара торгызачак. Зөлфия манарасы...

— Ә син, Зөлфия, кем булырга хыялланасың,— диде ул кызга иелеп.— Йосыф абый кебек, тарихчы булырсың инде, әйеме?

— Юк...— диде Зөлфия уңайсызланып кына. Аның тагы бит очлары кызарып чыкты, озын кара керфекләре түбән карадылар.— Мин җырчы булырга хыялланам... Борынгы җырларны бик яратам мин. Безнең әни бик моңлы итеп җырлый аларны. Ул җырлар үзләре бер тарих бит...

Алар шулай әкрен генә сөйләштеләр дә сөйләштеләр. Артта утырган Руслан юл буе аларга кызыгып кайтты. Берсе төзүче булам ди, икенчесе — җырчы. Ә Руслан кем булыр икән? Ул уйлар әле, уйлар... Бәлки, Йосыф абыйлары кебек, тарихчы булыр? Хәзинә эзләргә ярата бит ул... Руслан янәшәсендә утырган карт галимгә сыенарак төште. Ул Болгарга бөтенләй икенче кеше булып кайтуын сизде. Әнисе сөенер инде...

Самолет канаты астында Болгар җире күренде. Ямь-яшел урманнары, сабыр Иделе белән ул үзенең хәзинә эзләүчеләрен каршы алырга чыккан иде...

10 тиен.